**Шамиль Сагаутдинов**

# ИЛЛЕ ҖЫРЫМ – ЙӨРӘК НУРЫМ

# ПЯТЬДЕСЯТ ПЕСЕН – СВЕТ СЕРДЦА МОЕГО

Алматы 2015

УДК 784
ББК 85.314
С12

Рецензенты: Гатауллин Р.Х. , композитор, заслуженный деятель искусств Российской Федерации и Республики Татарстан, член союза композиторов РФ и РТ, лауреат премии им. М.Джалиля

Валиуллина Р.Н., кандидат искусствоведения, доцент

С12 Сагаутдинов Ш.Ш.

**Илле җырым – йөрәк нурым**. **Пятьдесят песен – свет сердца моего**. – Алматы, 2015. – 103 с.

ISBN 978-9965-20-759-4

Җыентыкта автор-башкаручы Шамиль Сагаутдиновның соңгы 20 ел эчендә иҗат иткән җырлары тупланды.

В сборнике представлены песни автора-исполнителя Шамиля Сагаутдинова, написанные им за последние 20 лет.

УДК 784
ББК 85.314

ISBN 978-9965-20-759-4

© Сагаутдинов Ш.Ш., 2015

*Минем сөекле апам*
*Гимаддинова Гариф кызы Рәшидәнең*
*якты истәлегенә багышлана*

# КЕРЕШ СҮЗ

Кадерле укучым! Сез кулыгызда тотып торган китапта минем соңгы 20 ел эчендә иҗат иткән җырларым тупланды. Түбәндә мин шушы әсәремә кыскача тасвирлама биреп үтәм.

Тематика буенча җыентыкны тәшкил иткән җырлар 7 бүлеккә бүленә:

1) «Туган илем – сөйгән җирем». Ватан, туган як турында җырлар.
2) «Безнең әти-әниләр – иң кадерле кешеләр». Бу бүлекне нибары ике җыр тәшкил итә: әтиләргә һәм әниләргә багышланган җырлар.
3) «Чын бәхет офыклары – мәхәббәт чаткылары». Мәхәббәт лирикасы.
4) «Иҗатым җимешләре – хатын-кыз исемнәре». Хатын-кыз исемнәренә багышланган җырлар.
5) «Җырлашып-биеп кенә». Бию җырлары һәм бәйрәмнәргә багышланган җырлар.
6) «Елмаеп-көлеп кенә». Күңелле һәм шаян җырлар.
7) «Китапның ахырында – төрле нәрсә турында». Тематика ягыннан классификацияләве читен җырлар.

Мелодика ягыннан тәкъдим ителгән барлык җырларны өч төркемгә бүләргә була. Шушы бүлү Земфира Сәйдәшеваның* хәзерге заман татар җырларын фәнни яктан тикшереп тәкъдим иткән классификациясенә туры килә:

«Беренче төркемгә татар халкының лирик җыр традицияләрен теге яки бу дәрәҗәдә дәвам итүче җырлар керә. Көйләре белән алар нигездә халыкның «авыл көйләре», «салмак көйләр», «кыска көйләр» дип аталган музыкаль жанрларына якын торалар». Бу төркемгә минем җырларымның өчтән бер өлеше керә: «Шахмай авылы», «Аулак өй кичәләре», «Кайтам туган ягыма» («авыл көйләре»), «Әнкәйгә теләкләр», «Лилия» («салмак көйләр»), «Чибәр кыз Гөлүсә», «Бәхетле бул, Нурия», «Дөрес әйтәсез, дуслар» («кыска көйләр») һәм башкалар.

«Икенче төркемгә көйләре нигезендә традицион мирастан бары тик метр (җөп өлеше) һәм темп (салмак яки тиз агышлы) сыйфатлары гына сакланып калган, әмма интонацион һәм ритмик яктан нык сизерлек үзгәрешләр кичергән җырлар керә». Мондый җырлар җыентыкның яртысын тәшкил итәләр: «Мин яратам сине, Казакъстаным», «Бүз тургайлы кырлар, карлыгачлы ярлар», «Әткәйгә сәлам», «Сәгатьләр», «Гөлнирәм», «Чикләвек», «Яңа ел җыры» һәм башкалар.

«Өченче төркемгә башка халыклар музыкасына хас аерым жанрларны тулысы белән файдаланган җырлар керәләр». Бу төркем җырлары дип «Җилләр исә»,

* Сәйдәшева З.Н. Хәзерге заман татар җырлары. – Казан: Казан дәүләт консерваториясе, 1997. – 11нче б.

«Гөлгенәм», «Котлы булсын туган көнең», «Әллә… микән?», «Хәерле юл» һәм калган барлык җырларны исәпләргә була.

Болай дип тә әйтергә ярыйдыр: беренче төркем җырлары – традицион («чиста») пентатоникада иҗат ителгән җырлар; икенченче төркемне пентатоникага нигезләнеп, ләкин шулай ук партитурага хроматика элементларын һәм альтерациянең очраклы билгеләрен кертеп язылган җырлар тәшкил итәләр; өченче төркем – пентатоника булмаган җырлар.

Аккордларның язылышы барлык партитураларда да традицион Европа системасына туры килә: *си* нотасы H хәрефе белән, *си бемоль* – B хәрефе белән билгеләнә; альтерация билгеләре иҗек белән языладар (*диез* – is, *бемоль* – es).

Тәкъдим ителгән барлык җырларның сүзләре татар телендә язылган. Аларның күбесен мин үзем иҗат иттем, калганнары Татарстан һәм Казакъстан шагыйрьләренең әсәрләренә нигезләп язылган.

Һәр җырның азагында аның исеменең рус теленә тәрҗемәсе һәм тиешле комментарий бирелә. Бу комментарийлар (шигъри һәм прозаик) – җыр сүзләренең тәрҗемәсе түгел, бары тик җырда телгә алынган нәрсәләр турында рус телендә фикер йөртү.

Ниһаять, китапка mp3-форматтагы 20 җырны үз эченә алган CD-диск теркәлә. Бу – авторның җыентыкны бастырып чыгарганга кадәр яздырып өлгергән җырлары. Дискта шулай ук язылган җырларның минусовкалары да бар. Җырлар аранжировкаларының авторы – күренекле Казан композиторы Ильяс Валишах. Ул шулай ук барлык җырларны гармонияләштерергә ярдәм итте һәм җыентыктың музыкаль редакторы эшен башкарды. Аның өчен мин аңарга зур рәхмәтлемен.

Шулай ук мин жыентык турында үз фикерләрен язган Риф Гатауллин белән Рәмзия Вәлиуллинага чиксез рәхмәтләремне әйтәсем килә.

Кереш сүзенең ахырында шуны да билгеләп үтим. Әлбәттә, тәкъдим ителгән җырларның кимчелек яклары юк түгел. Әмма ләкин аларның барлыгы да саф күңелдән һәм кешеләргә карата мәхәббәт хисе белән тулы йөрәктән язылган; шул турыда җыентыкның исеме дә әйтә: «Илле җырым – йөрәк нурым».

Җыентык турында үз фикерен язган һәр кешегә мин мең рәхмәтле булырмын. Фикерләрегезне үземнең электрон почта адресы буенча көтеп калам:

**shamil_sag@mail.ru.**

Китапны укуларыгыз һәм җырларны тыңлауларыгыз күңелгә ятышлы булсын!

*Ихтирам белән,*
*автор*

*Посвящается светлой памяти*
*моей любимой тети*
*Рашиды Гарифовны Гимаддиновой*

# ПРЕДИСЛОВИЕ

Дорогой читатель! Книга, которую Вы сейчас держите в руках, представляет собой собрание песен, написанных мной в течение последних 20 лет. Ниже я хотел бы кратко охарактеризовать предлагаемый мною труд.

По тематике песни сборника разбиты на 7 разделов:

1) «Туган илем – сөйгән җирем» («Родина – любимая земля моя»). Песни о родине, о родном крае.
2) «Безнең әти-әниләр – иң кадерле кешеләр» («Родители – наши самые дорогие люди»). В этом разделе всего две песни: посвящение отцам и матерям.
3) «Чын бәхет офыклары – мәхәббәт чаткылары» («Горизонты истинного счастья – это искры любви»). Любовная лирика.
4) «Иҗатым җимешләре – хатын-кыз исемнәре» («Женские имена как плоды творчества»). Песни, посвященные женским именам.
5) «Җырлашып-биеп кенә» («С песнями и танцами»). Танцевальные песни и песни, посвященные праздникам.
6) «Елмаеп-көлеп кенә» («С шутками и прибаутками»). Шуточные и юмористические песни.
7) «Китапның ахырында – төрле нәрсә турында» («В заключение – о разном»). Песни, которые сложно было отнести к какой-то конкретной тематической категории.

По мелодике все представленные песни можно разделить на три группы. Это разделение соответствует классификации, которую приводит Земфира Сайдашева*, характеризуя современные татарские песни:

«К первой [группе] отнесем песни, продолжающие в той или иной степени традиции фольклорной лирики татар, преимущественно в следующих жанрах: «авыл көйләре», «салмак көй», «кыска көй». Среди моих песен к этой группе относится примерно треть. Это такие песни, как «Шахмай авылы», «Аулак өй кичәләре», «Кайтам туган ягыма» (номинация «авыл көйләре»), «Әнкәйгә теләкләр», «Лилия» («салмак көй»), «Чибәр кыз Гөлүсә», «Бәхетле бул, Нурия», «Дөрес әйтәсез, дуслар» («кыска көй») и другие.

«Ко второй группе можно отнести песни, в мелодике которых от традиционных источников сохраняется лишь метр (четный) и темп (умеренный или быстрый), а в остальном музыкальное воплощение подвергается заметному интонационному и ритмическому обновлению». К этой группе можно отнести

* Сайдашева З.Н. Татарские современные бытовые песни. – Казань: Казан. гос. консерватория, 1997. – С. 21.

такие песни, как «Мин яратам сине, Казакъстаным», «Бүз тургайлы кырлар, карлыгачлы ярлар», «Әткәйгә сәлам», «Сәгатьләр», «Гөлнирәм», «Чикләвек», «Яңа ел җыры» и многие другие. Вообще, среди песен, вошедших в настоящий сборник, таких большинство – более половины.

«Третью группу составляют песни, в которых «иноязычные» жанры используются целиком». К этой группе можно отнести все оставшиеся песни сборника: «Җилләр исә», «Гөлгенәм», «Котлы булсын туган көнең», «Әллә… микән?», «Хәерле юл» и другие.

Можно сказать иначе, что первую группу составляют песни, написанные в традиционной («чистой») пентатонике; вторая группа – это песни, мелодической основой которых является пентатоника, но вместе с тем присутствуют хроматические элементы и случайные знаки альтерации в партитуре; третья группа – это песни, в которых пентатоника отсутствует.

Аккорды во всех партитурах записаны в соответствии с традиционной европейской системой: нота *си* обозначается буквой H, *си бемоль* – B; знаки альтерации имеют слоговые обозначения (*диез* – is, *бемоль* – es).

Тексты всех представленных песен написаны на татарском языке. Автором большинства из них являюсь я сам, остальные написаны на стихи известных татарстанских и казахстанских поэтов.

В конце текста каждой песни приводится ее название на русском языке и соответствующий комментарий. Хочу отметить, что данные комментарии, как стихотворные, так и прозаические, не представляют собой дословного перевода песенного текста. Это, скорее, размышления на тему данной песни, изложенные на русском языке.

И, наконец, к сборнику прилагается CD-диск с 20 песнями в mp3-формате. Это треки, которые автор сборника успел записать к моменту его выхода. Диск содержит также минусовки записанных песен. Автором аранжировок является известный казанский композитор Ильяс Валишах. Он же помог мне с гармонизацией мелодий и любезно согласился стать музыкальным редактором настоящего труда, за что я ему очень признателен.

Также хочу выразить свою благодарность Рифу Гатауллину и Рамзие Валиуллиной, взявшим на себя труд рецензирования данного сборника.

В заключение хочу заметить, что представленные песни, естественно, не лишены недостатков. Но все они написаны от души и с любовью к людям, о чем говорит название сборника: «Илле җырым - йөрәк нурым» – «Пятьдесят моих песен - свет сердца моего».

Буду признателен всем, кто выразит свое мнение о настоящем сборнике.

Ваши замечания и предложения жду по адресу своей электронной почты: **shamil_sag@mail.ru.**

Желаю приятного прочтения и прослушивания!

*С уважением,*
*автор*

# I БҮЛЕК

# Туган илем – сөйгән җирем

# МИН ЯРАТАМ СИНЕ, КАЗАКЪСТАНЫМ!




1. Иртә белән, таң атканда,
   Сандугачлар сайраганда
   Уяна минем туган илем –
   Таулары күккә чөелгән,
   Киң далалары җәелгән,

Күлләре тирән газиз җирем.

Таң атып, кояш уяну белән
Керешә эшкә безнең халык –
Гайрәтле дә, шәфкатьле дә,
Куәтле дә, белемле дә –
Ак бәхет телим сиңа, шатлык!

**Кушымта:**

Мин яратам сине, Казакъстаным –
Чын татулык дөньясы!
Мәңге яшь булып, яшә, Ватаным!
Син – безнең күз карасы!
(2 тапкыр)

2. Гомер буе онытылмас,
Күңелкәемнән җуелмас
Домбыраның җылы моңнары,
Астананың ал таңнары,
Алматының күк таулары,
Сарагачның шифа сулары!

Татар теле белән казакъ теле –
Икесе дә туган телләрем.
Курмангазы көйләрен дә,
Абайның шигырьләрен дә
Балачактан үз итте күңелем!

**Кушымта.**

3. Беркайчан да уйламам мин,
Беркайчан да омтылмам мин
Китәргә синнән башка илгә.
Сарҗайлау җилләре дә,
Акыннарның көйләре дә
Күңелемдә калыр мәңгегә!

Синдә – киләчәккә илткән юл да,
Синдә – иң якты өметләрем.
Ямьле табигать кочагы
Һәм мәдәният учагы,
Син – кендек каным тамган җирем!

**Кушымта.**

**Я люблю тебя, мой Казахстан!**

*Казахстан – Отчизна наша,*
*Нет тебя милей и краше!*
*Я горжусь своей судьбой,*
*Я всегда, навек с тобой!*

# 2. АЛМАТЫ ТУРЫНДА ҖЫР*




1. Якты йолдызлар җемелди
Алматының күгендә.
Мәңгелеккә сакланырсың
Йөрәгемнең түрендә.

Сандугачларың да синең
Моңлы итеп сайрыйлар,
Күбәләкләр, канат кагып,
Матур гөлләр сайлыйлар.

---

* Сүзләре Равил Гозәиров белән автордашлыкта язылган.

**Кушымта:**

Бик сагындым Алматымның
Каеннарын, талларын,
Бик сагындым Алматымның
Сызылып аткан таңнарын.

Сагындым газиз әнкәйне,
Бик сагындым сеңелемне!
Сагындым бар туганнарны,
Сагындым дусларымны!
Эх, сагындым Алматымны!

2. Аппак алма бакчаларың
Чәчәк ата майларда.
Тын кичләрең матурлана
Җәйге җылы айларда.

Кайда гына йөресәм дә,
Әйләнеп кайтам сиңа.
Таудан аккан суларың да
Шифа булдылар миңа.

**Кушымта.**

3. Җуелмасын беркайчан да
Алтыннан да зур байлык –
Казакъ белән татар халкы
Арасындагы дуслык.

Матурлансын Алматының
Урамнары, йортлары,
Яңгырасын Алматыга
Багышланган җырлары.

**Кушымта.**

**Песня об Алма-Ате**

Песня посвящена моему родному городу Алма-Ате (ныне Алматы) – южной столице Республики Казахстан.

*Распахнулся звёздный полог*
*Над тобой, Алма-Ата.*
*В самом деле, ты – не город,*
*А прекрасная мечта!*

*Каждый, кто на запад глянет,*
*Встав на гору Кок-Тюбе,*
*Вновь и вновь душой воспрянет*
*И поклонится тебе!*

*Есть на свете много главных,*
*Много важных городов,*
*Но один лишь город славный*
*Я всю жизнь любить готов,*

*Чья дорога не полога,*
*Не легка и не проста,*
*Город, что так сердцу дорог,*
*Чья пленяет красота, –*
*Ты, город мой Алма-Ата!*

# 3. ҖИЛЛӘР ИСӘ




1. Нинди ямьле безнең туган яклар:
   Киң елгалар, яшел тугайлар!

   Безнең куе урман хәтеремдә һаман:
   Иснәр идем хуш исләрен!
   Чыгар идем кырга яратып тыңларга
   Җәйге җилләрнең көйләрен!

**Кушымта:**

Җилләр исә, җилләр исә
Безнең якларда гына.
Җилләрем шулай искәндә
Йөрәгем дулкынлана!

Җилләр исә, җилләр исә,
Чайкала иген кыры.
Шул якларда мине сагынып
Көтә бит сөйгән ярым!

2. Туган авылым, сәлам сиңа, сәлам!
Сөям сине бар йөрәгем белән.

Монда күргәннәрем, гомер сөргәннәрем
Онытылмас, кайда йөрсәм дә.
Әнкәйнең көйләре, изге теләкләре
Мәңге яшәр күңелемдә.

**Кушымта.**

3. Илтте язмыш мине ерак җиргә.
Ярый микән язмышка рәнҗергә?

Хисләргә бирелеп, сагышка күмелеп,
Кичеп үтәм һәр төнемне.
Туган илкәемә, сөйгән җиркәемә
Әле кайтырмын бер көнне!

**Кушымта.**

**Ветры дуют**

*Ветры дуют, ветры дуют*
*Далеко, в родных краях.*
*Где зазывно ветры дуют,*
*Там живет любовь моя…*

# 4. БҮЗ ТУРГАЙЛЫ КЫРЛАР, КАРЛЫГАЧЛЫ ЯРЛАР






1. Гел төшемдә күрәм: су буенда чирәм,
   Без – балалар – суда йөзеп ярышабыз.
   Ярдан әнкәй төшә, кулын болгап дәшә:
   «Әй, балалар, җитәр сезгә! Тиз чыгыгыз!»

   Авылыма кайтсам, дусларымны күрсәм,
   Булыр иде дәва җаннарыма.
   Бүз тургайлы кырлар, карлыгачлы ярлар
   Гел чакыра мине яннарына... } 2 тапкыр

2. Менә кайттым тагын, сагынып туган якның
   Басуларын, болыннарын, чишмәләрен,
   Бар туганнарымны, иске дусларымны,
   Авылымның тиңдәше юк гүзәлләрен.

   Төрле җирдә булдым, төрле илдә тордым –
   Онытылмады яшьлек сукмаклары,
   Бүз тургайлы кырлар, карлыгачлы ярлар –
   Балачакның тугры юлдашлары! } 2 тапкыр

3. Әй, дусларым минем, кардәшләрем минем!
   Күреп кайттым төрле җирнең дәүләтләрен,
   Таудай биек йортлы, күлдәй иркен юллы,
   Матурлыгы искитәрлек шәһәрләрен.

   Чит илләрдә рәхәт, ләкин әйтәм кабат:
   Ямьләндерер мәңге күңелем түрен
   Бүз тургайлы кырлар, карлыгачлы ялар –
   Минем туып үскән газиз җирем! } 2 тапкыр

4. Җитәр тиздән тагын саубуллашу чагы,
Янә калыр еракларда туган ягым.
Газиз якташларым, иске юлдашларым!
Күрешергә насыйп булсын безгә тагын!

Кайда гына йөрсәм, кайда гына булсам,
Кайсы гына илдә яшәсәм дә,
Бүз тургайлы кырлар, карлыгачлы ялар
Мәңге яшәр минем күңелемдә!
} 2 тапкыр

**Жаворонковы поля, ласточкины берега**

Каждую ночь вижу я один и тот же сон из моего детства: мы с ребятами купаемся в речке за нашим аулом, с берега спускается мама и кричит нам: «Детишки, вам уже хватит! А ну-ка, выходите!» Если б побывал я в родных краях, нашла бы душа моя успокоение. Жаворонковы поля, ласточкины берега всегда манят меня к себе…

# 5. ШАХМАЙ АВЫЛЫ






1. Кама буйларында, туган якларымда
   Искән җилләр,
   Назлап күкрәгемне, арган йөрәгемне
   Җилкеттеләр.

   Искә төште безнең бабай салган өйнең
   Нигезләре,
   Таң нурлары төшкән
   Тәрәзләре.

   Төрле җирдә булдым, төрле илдә тордым –
   Шундый язмыш.
   Күп нәрсә күрсәм дә, туды йөрәгемдә
   Сары сагыш.

   Бик сагындым туган кырлар аша узган
   Олы юлны,
   Тау астында торган
   Авылымны.

**Кушымта:**

Шахмай авылына кайтсам,
Шатлана күңелләрем,
Шахмай авылына кайтсам,
Яңара өметләрем.

Шахмай авылы бик ямьле,
Шахмай авылы бик матур,
Шахмайдан башка мине ни юатыр? } 2 тапкыр

2. Менә кайттым тагын, сагынып авылымның
Ак өйләрен,
Нурдай балкып торган, тиңдәше булмаган
Гүзәлләрен.

Шахмай авылым минем, куенында синең
Үтте яшьлек.
Сиңа булган хисем –
Ул гомерлек.

Саумы, болыннарым, сайрар кошкайларым,
Тугайларым!
Саумы, Равил абый һәм Гөлфирә апа,
Туганнарым!

Саумы, Касыйм абый һәм Миңнаһар апа,
Саумы, дуслар!
Сагындырды сезнең
Моңлы җырлар!

**Кушымта.**

**Деревня Шахмай**

Песня посвящена деревне Шахмай Новошешминского района Республики Татарстан.

*Как живешь ты, край мой древний?*
*Край цветов – моя деревня!*
*Ты в душе всегда со мной.*
*Скоро ль свидимся с тобой?*

# 6. КАЙТАМ ТУГАН ЯГЫМА






1. Чит илләрдән туган илгә
   Кайтып киләм ашкынып,
   Каршы искән шаян җилгә
   Сәламемне тапшырып.

   Сәлам сиңа, илкәем,
   Туып үскән җиркәем!
   Сәлам сезгә, авылым,
   Басуларым, кырларым!

   Качып киткән улыгыз
   Кайта – каршы алыгыз!
   Гафу итә күрегез
   Һәм үпкәләмәгез!

2. Туган йортымның учагы
   Калса да ерак миннән,
   Әнкәйнең җылы кочагы
   Чыкмады күңелемнән!

   Сәлам сиңа, әнкәем!
   Сәлам, газиз әткәем!
   Сәлам сезгә, абыем,
   Апаларым, әбкәем!

   Качып киткән улыгыз
   Кайта – каршы алыгыз!
   Гафу итә күрегез
   Һәм үпкәләмәгез!

3. Истә калды кыр казларның
Һавадан үткәннәре,
Киткәнемдә яшь кызларның
Кочаклап үпкәннәре!

Сәлам сиңа, Әлфия!
Кара кашым – Зөлфия!
Гөлфия, Гүзәлия,
Рузалия-гөлкәем!

Югалган абзыегыз
Кайта – каршы алыгыз!
Гафу итә күрегез
Һәм үпкәләмәгез!

4. Чаба поезд, чак-чок итеп.
Озакламый җитәрмен.
Жырның ахырына җитеп,
Шагыйрьләрчә әйтермен:

Һинд илендә филләр күп,
Жир йөзендә илләр күп.
Арасында бай илләр,
Матур илләр дә бик күп.

Тик белмәс тинтәк кенә:
Туган як – ул бер генә!
Ни җитсен туган туфрагыңның
Исләренә?

Туган ягыма кайтам!

**Возвращаюсь в родные края**

Шаловливая песня от лица парня, который тайком уехал из своей деревни и теперь возвращается в родные края. По пути он мысленно представляет свою встречу с близкими людьми и просит у них извинения за свой побег.



# II БҮЛЕК

# Безнең әти-әниләр – иң кадерле кешеләр

# 7. ӘТКӘЙГӘ СӘЛАМ




1. Күпме сүзләр, изге теләкләр
   Шигырь булып, иңгән матур көйләргә!
   Без аларга кушып саф күңел хисләрен,
   Сәлам юллыйбыз әткәйләргә!

**Кушымта:**

Сәлам сиңа, әткәй, йөрәкләр түреннән!
Сәлам сиңа кызлар-уллардан!
Саклый күрсен Ходай сине җилләреннән,
Саклый күрсен авырулардан!

Нурлы көннәр белән тыныч төннәр теләп,
Рәхмәт әйтә сиңа балаларың –
Еллар буе эшләп түккән тирең белән
Сугарылып үскән гөлләрең.

2. Кырыс идең, әткәй, шулай да
Безнең өчен янды, көенде бәгырең.
Сирәк иде, ләкин бигрәк татлы иде
Безне иркәләп сөюләрең!

**Кушымта.**

3. Үстек, әткәй, бастык аякка,
Уку еллары да артта калдылар,
Ләкин безнең өчен гади киңәшләрең
Иң кыйммәтле сабак булдылар!

**Кушымта.**

**Привет отцу**

Песня написана ко дню рождения моего отца Шавката Гарифжановича Сагаутдинова. Посвящается всем отцам.

*Привет тебе, отец, из тайников сердечных!*
*С приветом словно сам к тебе лечу я!*
*За радость, за любовь, за негу дней беспечных –*
*За всё благодарить тебя хочу я!*

## 8. ӘНКӘЙГӘ ТЕЛӘКЛӘР






1. Бик тиз еллар үтте, куып бер берсен,
Балачак калды еракларда.
Ләкин әнкәйнең яшь чактагы төсе
Гел яши безнең йөрәкләрдә.

Елмаю нуры балкытсын йөзеңне,
Очыртсын борчу-кайгыларың!
Яшә, әнкәй, яшә, картайма мәңге,
Ямьле булсын алгы көннәрең!
} 2 тапкыр

2. Куарга теләп бар дөнья эшләрен,
Таралдык, киттек без еракка.
Тик йөрәгеңнең тылсымлы көчләре
Кайтарды безне туган якка.

Таң җилләре үпсен чәчләреңне,
Кошлар бүләк итсен көйләрен.
Яшә, әнкәй, яшә, картайма мәңге,
Ямьле булсын алгы көннәрең!
} 2 тапкыр

3. Балкысын кояштай нурлы йөзләрең,
Һич картаймасын синең йөрәк!
Безнең өчен, әнкәй, җылы сүзләрең,
Бар бүләкләрдән дә кыйммәтрәк!

Якты өметләр биләсен күңелеңне,
Сызламасын аяк-кулларың!
Яшә, әнкәй, яшә, картайма мәңге,
Ямьле булсын алгы көннәрең!
} 2 тапкыр

**Пожелания маме**

Песня написана ко дню рождения моей мамы Халиды Гарифовны. Посвящается всем матерям.

*В этот день прекрасный мы желаем снова:*
*Будь ты, мама, счастлива и всегда здорова!*
*Мы же, твои дети, будем с тобой рядом.*
*Только радуй, мама, нас своим ты взглядом!*

# III БҮЛЕК

## Чын бәхет офыклары – мәхәббәт чаткылары

# 9. СӘГАТЬЛӘР




1. «Сәгать ничә?» – дип сорадың,
Елмайдың, серле итеп.
Мин күзләреңә карадым,
Соравыңны онытып.

Шул минутта аңлаштылар,
Кавыштылар безнең йөрәкләр.
Ә бит, бәлки, очрашмас та идек,
Бу дөньяда булмаса сәгатьләр!

**Кушымта:**

Кызарып яна шәфәкъләр,
Яңадан таңнар туа.
Туктаусыз йөри сәгатьләр,
Телләрен куа-куа.

Сәгать күпме генә йөрсен,
Бергә була телләре.
Гел шулай, берлектә үтсен
Сөйгән яр гомерләре!

2. Үтәр кышлар, үтәр җәйләр,
Агар вакыт ташкыны,
Бер дә тынмас яшь йөрәкләр,
Табышырга ашкыныр.

Барлык парлыларның гомерләре
Булсын иде бәхетле!
Кавышу сәгатьләре, барасы юллары
Булсын иде хәерле!

**Кушымта.**

**Часы**

Стрелки часов то сходятся, то расходятся, но все равно они всегда вместе. Пусть же и влюбленные, как стрелки часов, никогда не расстаются друг с другом.

# 10. МИНЕМ МӘХӘББӘТЕМ*




* Әтием Шүәкәт Сагаутдинов белән автордашлыкта язылган.

1. Җил җырларын тыңлап йөрдем
Агыйдел буйларында.
Сине күргәч, матур җырлар
Уянды йөрәгемдә.

Синең якты күзләреңә
Бер генә караш салдым.
Бәхет кошның иңбашыма
Кунганын гүя сиздем.

2. Сандугачым, әйтеп сайра
Мәхәббәт серләремне.
Үзем никтер каушап калам:
Онытам сүзләремне.

Әйтеп бир мәхәббәтемнең
Якты һәм пакь булганын,
Аңлатып бир күңелемнең
Бер аны уйлаганын.

3. Карлыгачкаем минем син!
Бөтен күңелем синдә.
Минем кебек бәхетле җан
Юктыр дөнья йөзендә.

Күзләрем мәңге туймас ла,
Күреп нурлы йөзеңне.
Алладан сораганым шул:
Аерма, Ходам, безне!

**Моя любовь**

Ласточка моя! Вся душа моя полна тобой. Нет на земле более счастливого человека, чем я! Никогда мои глаза не устанут любоваться тобой. Одного лишь я прошу у Аллаха: не разлучай нас, о великий Боже!

# 11. МӘХӘББӘТ СҮРЕЛМИ






1. Кыш үтте, яз килде,
   Ага су ташкыны.
   Су кебек, йөрәгем
   Талпына ашкынып.

**Кушымта:**

Синең нурлы йөзең
Күңелемне яндыра,
Якты күзләрең мине
Гел куандыра.
} 2 тапкыр

2. Яз үтте, җәй килде,
   Җир йөзе ямьләнә,
   Ә минем өчен ямь –
   Син генә, син генә.

**Кушымта.**

3. Җәй үтте, көз җитте,
   Сибәли яңгырлар.
   Тик алар сөюне
   Сүндерә алмаслар.

**Кушымта.**

4. Көз үтте, кыш җитте,
   Кар ява урамда.
   Тик йөрәк ялкынын
   Җиңалмас буран да.

**Кушымта.**

5. Яшьлек мәңге булмас,
   Тик беләм мин шуны:
   Мәхәббәт сүрелмәс,
   Вакыт җиңмәс аны.

Картайсак та, йөзең
Күңелемне яндырыр,
Якты күзләрең мине
Гел куандырыр!
} 2 тапкыр

**Любовь не проходит**

Осень сменяет лето, вслед за зимою приходит весна. Но палит ли солнце или метет пурга, – моя любовь к тебе всегда крепка и не подвержена превратностям погоды и времени. Даже когда мы состаримся, твой нежный взор будет также волновать меня!

# 12. ЯННАРЫМДА СИН БУЛГАНГА




1. Вәгъдәләштек гомерлеккә,
   Бергә булырбыз диеп,
   Мәхәббәт утын сүндерми
   Гөрләп яшәрбез диеп.

   Яшәрбез диеп,
   Яшәрбез диеп,
   Мәхәббәт утын сүндерми
   Яшәрбез диеп.
   } 2 тапкыр

2. Кушылды безнең сулышлар,
Ярсып типте йөрәкләр,
Безгә бәхет теләгәндәй
Чайкалдылар тирәкләр.

Зифа тирәкләр,
Зифа тирәкләр,
Безгә бәхет теләп калды
Зифа тирәкләр. } 2 тапкыр

3. Гомерлеккә сөйдем сине,
Син бит минем бер генәм.
Шатлыгым да, өметем дә,
Бәхетем дә син генә!

Тик син, бер генәм,
Тик син, бер генәм,
Өметем дә, бәхетем дә
Тик син, бер генәм! } 2 тапкыр

4. Яннарымда син булганга
Мин яшимен куанып,
Нурлы йөзләреңә карап,
Бала кебек юанып.

Яшим куанып,
Яшим куанып,
Яннарымда син булганга
Яшим куанып! } 2 тапкыр

**Потому что ты рядом**

Полюбил тебя навек я. Ты – моя радость, моя надежда, моё счастье. Я смотрю в твои лучистые глаза и радуюсь, как ребёнок, потому что ты рядом.

# 13. АЙ СӨЯРМЕН, ЕЛ СӨЯРМЕН*




* Рифгат Закиров сүзләре.




1. Тик бер генә күз төшердем
Нурлы йөзләреңә,
Тик бер генә күз төшердем
Сиңа, матурым,

Ай күрендең, ел күрендең
Моңсу күзләремә,
Гел күрендең күзләремә,
Асыл ярым!
} 2 тапкыр

2. Ал димәдем, ял димәдем,
Шәүләңә ымсынып,
Ал димәдем, ял димәдем –
Гиздем Җир шарын.

Ай эзләдем, ел эзләдем,
Йөзеңне юксынып,
Гел эзләдем сине, бәгърем,
Асыл ярым!
} 2 тапкыр

3. Бел, янмасаң әгәр дә син
Сөю утларында,
Бел, янмасаң әгәр дә син,
Жәлләп күңелеңне,

Ай көярсең, ел көярсең,
Юксынып ярыңны,
Гел көярсең, бәгырькәем,
Уйлап мине!
} 2 тапкыр

4. Тик син генә, асыл ярым,
Шатлыгым, гамьнәрем!
Тик син генә, асыл ярым,
Илһамнарым!

Ай сөярмен, ел сөярмен
Сине, җан дускаем,
Гел сөярмен сине, бәгърем,
Асыл ярым!

2 тапкыр

**Буду любить тебя месяц, буду любить тебя год**

Один лишь взгляд бросил я на тебя, милая, и ты навсегда запала мне в сердце. Только ты, родная, моя радость, моя забота, моё вдохновение. Буду любить тебя месяц, буду любить тебя год, буду любить тебя всю жизнь!

# 14. БИК САГЫНДЫМ СИНЕ




1. Кабат-кабат йомам күземне,
   Кабат күрәм шуны ачык:
   Чумып басу киңлекләренә,
   Китәсең син, миннән качып.

Әгәр бер киткән бу юлыңнан
Кайтмасыңны белгән булсам,
Куып җитеп, тотып кулыңнан
Һич җибәрмәс идем бүтән!

**Кушымта:**

Бик сагындым сине,
Шаян күзләреңне,
Һаман уйлап сине
Яна күңелләрем.

Тапсам сине, иркәм,
Кочып иңнәреңнән,
Үбеп күзләреңнән,
Сөяр идем, бәгърем!

2. Айлар, еллар аерды безне.
Ялгыз үтте яшь гомерем.
Табалмадым мин синең эзне,
Табалмадым сине, бәгърем.

Тик тирбәлә шәүләң еракта.
Кайда соң син, кайсы якта?
Бөтен уйларым синең хакта,
Бар җырларым синең хакта!

**Кушымта.**

3. Кабат-кабат йомам күземне,
Кабат күрәм шуны ачык:
Чумып басу киңлекләренә,
Китәсең син, миннән качып.

Нигә кайчак үпкә таплары
Каплый икән күңел күзен?
Иркәм! Әйбәтме тормышларың?
Бәхет таптыңмы соң үзең?

**Кушымта.**

**Я очень соскучился по тебе**

Вновь и вновь закрываю я глаза и вижу, как, затаив обиду в душе, ты уходишь от меня. Если бы я знал, что больше никогда не увижу тебя, то догнал бы и больше никогда не отпускал от себя. Вернись же ко мне, родная, прости меня! Ведь я так люблю тебя!

# 15. КАВЫШЫЙК БЕЗ*




1. Бик күп йөрдем, дөнья гиздем,
   Арыды йөрәккәем.
   Арыган йөрәккәемә
   Шифа булчы, гөлкәем!

**Кушымта:**

Кавышыйк без, кем булсак та,
Бергәләп тормыш корыйк!
Сер дә, кул да бирмик ятка,
Гомергә бергә булыйк!

2. Диңгез булсаң, мин каршыңа
   Агармын елга булып.
   Мин агармын, син торырсың
   Гел мөлдерәмә тулып.

**Кушымта.**

3. Төн булсаң, йолдыз булырмын,
   Көн булсаң – якты кояш.
   Җил булсаң, давыл булырмын –
   Барыбер минсез булмас!

**Кушымта.**

---

* Рифгат Закиров сүзләре.

**Будем вместе**

*Нам не грустно, нам не скучно*
*Под одною крышей жить.*
*Будем впредь мы неразлучны,*
*Будем счастьем дорожить!*

# 16. БЕР СИН ГЕНӘ




1. Син булганга күрә алдым дөнья ямен,
   Син булганга сизә алдым яшәү тәмен.
   Синең күзләр җанландырды йөрәгемне,
   Күптән сүнеп калган өметемне.

**Кушымта:**

Синең белән китәр идем еракларга,
Синең белән очар идем йолдызларга.
Бер син генә аңлый аласың серемне,
Назлый аласың күңелемне.

2. Син булганга кояш балкыйдыр яктырак.
   Син булганга җилләр исәдер йомшаграк.
   Син булганга утны, суны кичү рәхәт!
   Син булганга, бәгърем, сиңа рәхмәт!

## Кушымта.

**Лишь ты одна**

*Лишь ты одна меня вернула к жизни вновь.*
*Лишь ты одна в моей душе зажгла любовь.*
*Я без тебя бродил по жизни как в бреду,*
*Не знал, где счастье я найду.*

*Но день настал, и вот с тобою рядом я.*
*Ты мой кумир, мой нежный луч, любовь моя!*
*Как счастлив я, что нашу жизнь Бог озарил,*
*Что Он любовь нам подарил!*

# 17. ЖИЛ




1. Гел төшерәм исемә шул көзге көнне:
   Юл чатында күрешүне,
   Җан дускайның күзләренә төбәп күзне,
   Кавышырга килешүне.

   Мин сөйгәнемә әйттем: «Ай калку белән
   Күл буена кил, иркәм, кил!»
   Белмим, шул күл буенда ник үтте икән
   Арабыздан бер салкын җил?

**Кушымта:**

Җил, җил, җил
Кискәли битемне,
Өзгәли күңелемнең саф кылларын.

Җил, җил, җил!
Әйтче, дустым, шуны:
Кайда минем яшьли сөйгән ярым?

2. Сиңа, җилкәй, ияреп китәр идем мин
Еракларга, еракларга.
Сөйгәнемне эзлим дип, очар идем мин
Йолдызларга, йолдызларга.

Бер карасаң, йолдызлар бик матур, ләкин
Бигрәк салкын йолдыз нуры.
Һич җылыталмас ул күңелеңне, әгәр
Киткән булса сөйгән ярың!

**Кушымта.**

3. Җил, дускаем, очып бар син гөлкәемә,
Җиткер аңа сәламемне
Һәм аңлатып бир, зинһар, бәгырькәемә
Кайнар сөю хисләремне!

Очырт аның күңелендәге болытларны:
Якты кояш кабат чыксын!
Әйтче аңа: гафу итеп кылыгымны
Яннарыма тизрәк кайтсын!

**Кушымта.**

**Ветер**

О ветер! Ты стал свидетелем нашей размолвки. Помоги же нам помириться и вновь обрести друг друга!

## 18. ҮБӘР ИДЕМ КҮЗЛӘРЕҢНӘН






1. Нигә, нигә таң җилләре
Бөккәлиләр тирәкләрне?
Нигә үкенү хисләре
Кискәлиләр йөрәкләрне?

**Кушымта:**

Үбәр идем күзләреңнән:
Бик сагындырды күзләрең!
Барыр идем эзләреңнән:
Бик ерак синең эзләрең!

2. Хатамны беләм, гөлкәем:
Авыр сүзләр әйттем сиңа.
Тик белеп кал, бәгырькәем:
Хәзер бик үкенәм шуңа!

**Кушымта.**

3. Хатлар язам, тагын язам,
Җавап бирмисең аларга.
Барыбер беләм, җанкаем:
Күңелең төшмәс ятларга!

**Кушымта.**

4. Һава гел болытлы булмас:
Яңгырдан соң кояш чыга.
Күңел гел рәнҗүле булмас:
Үпкәләрең чыгар юкка!

**Кушымта.**

**Поцеловал бы я твои глаза**

Пошел бы я по твоим следам, поцеловал бы тебя в глаза, да не могу: слишком далеко ты от меня!

# 19. СҮНМӘСЕН ӨМЕТЛӘРЕҢ




1. Әллә тормыш җафалары
Тәмам җиткән башыңа?
Әллә үпкә орлыкларын
Кемдер салган җаныңа?

Ник болытлар каплады соң
Саф күңелең кояшын?
Дәшче, иркәм,
Бигерәк сагындырды бит
Синең назлы тавышың!
} 2 тапкыр

2. Иң беренче күрүемнән
Шундый яраттым сине!
Чын бәхетнең килүе дип
Каршыладым шул көнне.

Ник соң тынды былбылкаең
Синең күңел бакчаңда?
Бел: яныңда
Гел булырмын, җанкаем, мин,
Елга булып аксаң да!
(2 тапкыр)

3. Шаһит булсын бу сүзләргә
Күктәге йолдызкаем.
Безнең иң саф теләкләрне
Кабул итсен Ходаем!

Ник җаныңны кайгы өтә?
Нигә моңсу күзләрең?
Алда безне
Бәхетле көннәр көтә, тик
Сүнмәсен өметләрең!
(2 тапкыр)

**Пусть не гаснет твоя надежда**

Трудно бывает порою в жизни, любимая, но ты не отчаивайся: что бы ни случилось, я всегда буду рядом с тобой.



# IV БҮЛЕК

## Иҗатым җимешләре – хатын-кыз исемнәре

# 20. АКЙОЛДЫЗ




1. Ишеткән идем күптән мин: күк йөзендә
   Бар икән дип бер матур нурлы җисем.
   Ак йолдыз дигән исеме бар шул җисемгә
   Бик килә, дуслар, минем бер җитәсем!

**Кушымта:**

Ак йолдыз нурларын җырлый-җырлый җыяр идем,
Бергә үреп, ясар идем нур бәйләмнәрен.
Акйолдыз исемле матур кызга бирер идем,
Бәйләмгә кушып, йөрәгем хисләрен!

2. Әгәр булса иде көчле коралларым,
   Ак йолдыз серен тиздән ачар идем.
   Әгәр булса иде көчле канатларым,
   Кош булып, Ак йолдызга очар идем.

**Кушымта.**

3. Күк йөзендә Ак йолдызны эзли-эзли
Арыды шул ике күз кабакларым.
Барыбер очып җитәрмен шул йолдызга,
Киң җәеп матур хыял канатларын!

**Кушымта:**

Ак йолдыз нурларын җырлый-җырлый мин үрермен,
Һәм, бергә кушып, ясармын нур бәйләмнәрен.
Акйолдыз исемле матур кызга мин бирермен,
Бәйләмгә кушып, йөрәгем хисләрен!

**Акъюлдуз**

Песня посвящена девушкам по имени Акъюлдуз.

Сюжет песни построен на значении имени Акъюлдуз – «белая звезда». Герой песни представляет себе, что где-то во Вселенной есть звезда под названием Ак юлдуз (Белая звезда). Он мысленно совершает по ней путешествие, собирает лучи, сплетает их в венки и дарит своей возлюбленной – девушке по имени Акъюлдуз.

# 21. ГӨЛГЕНӘМ






1. Гел керәсең карурман эченә,
Гел тыңлыйсың, кызыгып, күкене.
Сокланасың чишмәләр көенә,
Тик ишетмисең минем көемне.

Килче, килче, бәгырькәй, яныма!
Булчы минем гомерлек юлдашым!
Син генә дәва көйгән җаныма!
Син генә бит минем күңел кошым!

**Кушымта:**

Гөлгенәм, Гөлгенәм!
Син бит минем бер генәм!
Күз нурым, җанашым,
Минем назлы кояшым!
} 2 тапкыр

2. Фәрештә түгел син – гади генә
Авыл кызы булсаң да күпләргә,
Мин сөйдем сине, кояш иттем дә
Күтәрдем, чөеп, зәңгәр күкләргә.

Сөям сине! Минем төсле итеп
Сөймәгән хәттә Мәҗнүн Ләйләсен!
Шулай булгач, якты кояш кебек,
Минем өчен янмас идеңме син!

**Кушымта.**

**Гульгина**

Песня посвящается девушкам по имени Гульгина.

*Гульгина! Гульгина!*
*Ты в душе моей одна –*
*Нежный свет, солнца луч,*
*Разогнавший стаи туч!*



# 22. ГӨЛНАЗЫМ




1. Төн каплады инде күптән дөнья йөзен.
Ай, йокыга талып, йомды сары күзен.
Җил, исә-исә, арыды инде бугай.
Туктатты җырын сары тургай.

Бер мин генә дәва табалмыйм җаныма.
Ник бер дә килмисең, иркәм, яннарыма?
Ник аңларга теләмисең хисләремне,
Җыр аша әйткән сүзләремне:

**Кушымта:**

Гөлназымның күзләрендә
Чагыла дөнья яме.
Гөлназымны күрми калсам,
Югала яшәү тәме!

Син – аем да, кояшым да,
Син – күтәп алган язым!
Һәрвакыт күңелләремдә
Минем назлы Гөлназым!

2. Көй аркылы аңларсың дип сагышымны,
Мин җибәрәм яннарыңа сандугачны.
Мин, нур булып, үбәм сине күзләреңнән,
Җил булып, сыйпыйм чәчләреңнән.

Бел: эшләсәң дә мең тапкыр үзеңнекен,
Син барыбер, иркәм, булырсың минеке!
Бел: ачмый калмас күңелеңнең бикләрен
Җыр аша әйткән сүзкәйләрем:

**Кушымта.**

**Моя Гульназ**

Песня посвящена девушкам по имени Гульназ.

Чтобы ты поняла мою грусть, я отправляю к тебе с песней соловья. Я, став лучом, целую твои глаза. Став ветром, глажу твои волосы.

Упирайся, хоть тысячу раз стой на своём – все равно ты будешь моей! Потому что не сможет не растопить девичье сердце песня, спетая от души.

# 23. ГӨЛНИРӘМ






1. Җанкаем серле итеп көлгәндә
 Нурлана шаян күзкәйләре.
 Җисеменә исеме туры килгәндәй,
 Бик матур аның исемнәре.

**Кушымта:**

Гөлнирәм! Гөлнирәм!
Күңелемнең назын бирәм,
Бары тик сиңа бирәм, җанкаем!
Сагындым! Ни хәл итим, иркәм?

Гөлнирәм! Гөлнирәм!
Син бит минем җан парәм!
Күрә алмасам да өннәремдә,
Төшемдә сине һәр төн күрәм. } 2 тапкыр

2. Бик кырыс икән шул язмышкаем –
 Үземне һаман кызык итә:
 Казанда яши минем җанкаем,
 Чит илдә тормышкаем үтә.

**Кушымта.**

3. Басылыр әле тормыш бураны,
 Кавышу көне җитәр әле.
 Хәзергә исә ерак араны
 Бу җырым якын итәр әле!

**Кушымта.**

**Моя Гульнира**

Песня посвящена девушкам по имени Гульнира.

*Гульнира! Светик мой! Ты – в Казани,*
*Я – в далеких суровых краях.*
*Но я рад всё равно несказанно,*
*Что ты есть у меня, жизнь моя!*

*Как спою – ты становишься ближе,*
*Только песня мне может помочь.*
*Днем тебя я, конечно, не вижу,*
*Но во сне вижу каждую ночь!*

# 24. ЧИБӘР КЫЗ ГӨЛҮСӘ




1. Асыл ташлар арасыннан
   Яратам фирүзәне.
   Матур кызлар арасыннан
   Яратам Гөлүсәне.

      Диңгездә җилләр исә,
      Бакчада гөлләр үсә.
      Кем бәхетенә үскән икән
      Чибәр кыз Гөлүсә?

2. Алмагачтан алма төшеп,
   Җирләрне уяр микән?
   Гөлүсәне кабат күреп
   Күзләрем туяр микән?

      Алма төшәр микән,
      Җирне уяр микән?
      Гөлүсәне кабат күреп
      Күзем туяр микән?

3. Бакчадагы гөлләремнең
   Тамырлары бер генә.
   Кайчан да бер күрешербез –
   Белмим көннәрен генә!

      Ай, көннәрен генә,
      Вай, көннәрен генә!
      Күрешербез – белмим, бәгърем,
      Тик көннәрен генә!

4. Һавадагы йолдызларны
Нигәдер санамадым.
Күз тияр дип йөзләреңә
Нигәдер карамадым.

Йолдыз санамадым,
Бәхет сынамадым,
Күз тияр дип йөзләреңә
Никтер карамадым.

5. Су буена бармас идем,
Су салкынын сизмәсәм.
Өзелеп җырлар язмас идем,
Гөлүсәне сөймәсәм.

Өзелеп сөймәсәм,
Сөюдән көймәсәм,
Синең өчен җан бирергә
Әзерлек сизмәсәм.

6. Җыр язам мин сиңа,
Ник язмыйсың миңа?
Җыр язам мин сиңа,
Ник язмыйсың миңа?

Син бит былбыл кебек миңа,
Мин ничек соң сиңа?
Син былбыл күк миңа,
Мин ничек соң сиңа?

7. Аклы ситсы күлмәгеңне
Өстәлләрдә кистеңме?
Йөзең гөлләргә охшаган,
Гөл эчендә үстеңме?

Күрсәт, бәгърем, үзеңне,
Нур сипкән йөзләреңне!
Көндәй ямьле, балдай тәмле
Зәңгәр күзләреңне!

8. Асыл ташлар арасыннан
Яратам фирүзәне.
Матур кызлар арасыннан
Яратам Гөлүсәне.

Диңгездә җилләр исә,
Бакчада гөлләр үсә.
Ак бәхетләр телим сиңа,
Чибәр кыз Гөлүсә!

**Красавица Гулюса**

Песня посвящается девушкам по имени Гулюса.

*Средь камней и гор великих*
*Всех красивей бирюза.*
*Средь девчонок белоликих*
*Всех красивей Гулюса.*

*Если в море ветер свищет,*
*То лишь тишь – в земных краях.*
*Красотою с детства блещет*
*Гулюса – любовь моя.*

*Все цветы в моем саду*
*Вскормлены одной рекой.*
*Где, когда, в каком краю –*
*Свидимся ли мы с тобой?*

## 25. ГӨЛФИЯ



1. Яз җиткәч, кошлар кайталар,
Сагынып туган якларын.
Сайрый-сайрый уяталар
Мәхәббәт чаткыларын.

Язгы кичләрнең берсендә
Тәрәз төбеңә килдем.
Гармунымны кулга алып,
Исемеңне көйгә салып,
Шушы жырны җырладым:

**Кушымта:**

Гөл-гөл-гөл-гөл-гөл-гөл-Гөлфиянең
Бигрәк матур тавышы!
Гөл-гөл-гөл-гөл-гөл-гөл-Гөлфиянең
Сызылып тора кашы!

Гөл-гөл-гөл-гөл-гөл-гөл-Гөлфиянең
Шаян икән күзләре!
Гөл-гөл-гөл-гөл-гөл-гөл-Гөлфия, җанкаем!
Рәхәт үтсен көннәрең!

2. Язлар үтте, үтте җәйләр,
Менә көзләр дә җитте.
Көньякка киткән кошлардай
Яшь вакыт үтеп китте.

Тик һаман яши күңелдә
Тәүге сөю хисләрем,
Гармунымны кулга алып,
Исемеңне көйгә салып,
Сиңа әйткән сүзләрем:

**Кушымта.**

**Гульфия**

Посвящается девушкам по имени Гульфия.

Помнишь, Гульфия, как брал я в руки гармонь, играл под твоими окнами и пел для тебя? Эх, вернуть бы те деньки золотые!..



# 26. ГҮЗӘЛИЯ




1. Безнең авыл – тау башында.
   Тирәкләре күккә тия.
   Бер чибәр кыз яши монда.
   Исеме аның – Гүзәлия.

   Чәче бигрәк матур була,
   Җилфердәтеп бер тараса.
   Күңелемә рәхәт була,
   Елмаеп караса!

**Кушымта:**

Гүзәлия, Гүзәлия!
Бөтен кеше аны сөя.
Сәләтләре чиксез аның,
Тырышлыгы – бинибая!

Гүзәлия, Гүзәлия!
Күзе – шомырт, ирене – чия.
Йөрәккәемдә ут кабынды,
Гүзәлия дия, дия! } 2 тапкыр

2. Гүзәлияне очратсам,
Бар кайгыларым тарала.
Гүзәлиягә сүз катсам,
Күңелем сафлыкка урала!

Гүзәлия, алсу гөлем!
Нур сибелсен юлларыңа!
Алсу гөлем, саф күңелем
Бүләк итәм сиңа!

**Кушымта.**

**Гузелия**

Посвящается девушкам по имени Гузелия, Гузель.

*Гузелия, Гузелия!*
*Под стать луне краса твоя!*
*С тех пор, как я тебя увидел,*
*Горит огнем душа моя!*

# 27. ДИЛБӘР, ДИЛБӘРКӘЕМ






1. Таң җилләре искән чакта
Су өсте дулкынлана.
Дулкын булып, яшь йөрәгем
Өзгәләнә, моңлана.

**Кушымта:**

Эх, Дилбәр, Дилбәркәем!
Синнән башка яшәүнең лә
Тоймыйм һич ямен, тәмен дә,
Минем назлы гөлкәем!

Эх, Дилбәр, Дилбәркәем!
Яралама йөрәгемне!
Синең нурлы йөзләреңне,
Синең татлы сүзләреңне,
Сөю тулы күзләреңне,
Әйтче, ничек онытаем?

2. Бергә үстек, бергә йөрдек,
Вәгъдәләштек мәңгегә.
Әйтче: нигә күңелкәең
Кинәт төште бүтәнгә?

**Кушымта.**

3. Маңгай күзе алдаса да,
   Күңел күзе алдамас.
   Белеп тор: синең күңелең дә
   Хатасын сизми калмас!

**Кушымта.**

**Дильбар, Дильбарушка**

Песня посвящена девушкам по имени Дильбар.

Эх, Дильбар, Дильбарушка! Без тебя я не чувствую вкуса к жизни! Не рань моё сердце! Разве смогу я позабыть твой лучистый лик, твои нежные слова, твои глаза, полные любви?

# 28. ШӘРЫК КЫЗЫ ЗӘРИНӘ






1. Көн бигрәк ямьсез иде,
Җил бигрәк әрсез иде:
Котырды, тинтерәтеп өрекләрне.
Ләкин бер кояш нуры
Болытны чыкты ярып.
Шул минутта очраттым юлда сине.

Яныңнан узып, нәрсәдер сизеп,
Әйләнеп, сиңа карадым.
Якты нурыңнан дәрт алган сыман,
Шул дәрткә кинәт тарыдым!

**Кушымта:**

Эх, Зәринә, Зәринә,
Шәрык кызы Зәринә!
Туймыйм һич, карап нурлы йөзләреңә!

Эх, Зәринә, Зәринә,
Кердең күңелем түренә!
Йолдызкаем, җан дускаем, Зәринә!

2. Айдай кыйгач кашларың,
Төндәй кара чәчләрең
Әсир иттеләр күңелемне мәңгегә.
Язмышка мин рәхмәтле:
Ничек соң илтте әле
Ул мине син яшәгән матур җиргә?

Нурлы илеңне, серле телеңне
Мин дә үз иттем, яраттым.
Еллар буена тик сине генә
Эзләгәнемне аңладым!

**Кушымта.**

**Восточная красавица Зарина**

Посвящается девушкам по имени Зарина.

*Помню: дождь угрюмо лил,*
*Ветер грозно в окна бил*
*И шумел, листву деревьев теребя.*
*Но однажды из-за туч*
*Вдруг пробился солнца луч,*
*В этот самый миг увидел я тебя.*

*И прошли дожди, стихли вдруг ветра,*
*И запели птицы в садах.*
*И увидел я чудный свет зари*
*В твоих нежных, милых глазах!*

*С той поры в душе моей*
*Наступила вдруг весна.*
*Имя той весны – Зарина, Зарина.*
*Эх, Зарина, Зарина,*
*Вся душа тобой полна,*
*Лишь тобой одной, Зарина, Зарина!*

## 29. ЛИЛИЯ




1. Хəтерлим һаман мин татлы төштəй
   Безнең танышкан тəүге көнне.
   Бер күрүдəн сиңа күңелем төште!
   Яраттым гомерлеккə сине!

   **Кушымта:**

   Лилиям!
   Бары тик сине, иркəм, сөям!
   Җанашым!
   Ходай насыйп иткəн юлдашым!

2. Синең пакь күңелең, саф йөрəгең
   Тиңлим челтер чишмə суына.
   Ышанычлы дустың, нык терəгең
   Мин булырмын гомер буена!

**Кушымта.**

3. Кояш ак нурыннан киң шәл тегеп,
Җилкәләреңә назлап салсын!
Туган-дусларыбыз безнең кебек
Гомер буе бәхетле булсын!

**Кушымта.**

**Лилия**

Эта песня – признание в любви моей жене Лилии – самой прекрасной девушке на Земле.

# 30. БӘХЕТЛЕ БУЛ, НУРИЯ!




1. Киртәләргә элеп куйган
Эшләпәм тузды инде.
Нурия дип җырлый, җырлый,
Гомерем узды инде.

**Кушымта:**

Сине күреп, күзем туймый,
Һаман килә күрәсем!
Йөзләреңдә нурлар уйный,
Син чынлап нур иясе!

Саф йөрәгең алларында
Һәрвакыт мин баш иям.
Кадерле бул, сөекле бул,
Бәхетле бул, Нуриям!

2. Иртә белән уянам да,
Уйлыйм синең турында,
Сөю утларында янам,
Йөзәм назлы нурында.

**Кушымта.**

3. Күз тутырып, бер карачы,
Күңелең тулмаса да,
«Яратам сине!» – дип әйтче,
Ул шулай булмаса да!

**Кушымта.**

**Будь счастлива, Нурия!**

Песня является как бы продолжением татарской народной песни «Нурия»:

Шляпа, которую я повесил на изгородь, уже давно обветшала. С песней «Нурия» вся жизнь моя прошла.

Я смотрю на тебя, и мне хочется утонуть в твоих глазах. Я всегда преклоняюсь перед твоей чистой душой. Будь дорога, будь любима, будь счастлива, Нурия!

# 31. РЕЗЕДА, БӘГЫРЬКӘЕМ






1. Тугайларда ал чәчәкләр җыясыңмы?
Тугайларны су назлап дулкынлана.
Айга карап күз нурларын коясыңмы?
Безне ай эзләп, тын алмый, моңлана.

**Кушымта:**

Резеда, бәгырькәем! Ник килмисең, гөлкәем?
Күптәннән сүнгән инде шәфәкъ нуры.
Әйтче, нигә көн буе күңелең синең боек?
Моңланасың нигә? Әйт миңа туры!

Резеда, бәгырькәем! Минем назлы гөлкәем!
Сайрый, сайрый арыган сандугачлар.
Бирче, иркәм, кулыңны! Аччы миңа сереңне!
Сердәш булсын безгә тәүге йолдызлар!

2. Сине сагынып, дулкын ярны кыйный бугай,
Уйчан таллар тик сине уйлый бугай.
Нигә качтың, кая качтың соң син шулай?
Яшерде эзләреңне куе тугай.

**Кушымта.**

3. Яратам мин сине генә, сизәсеңме?
Кумассың бит, яныңа үзем килсәм?
«Башканы сөям бит шул!» – дип әйтмәссеңме,
Саф йөрәгемне сиңа бүләк итсәм?

**Кушымта.**

**Резеда, душа моя**

Песня посвящена девушкам по имени Резеда.

Резеда, душа моя! Почему ты не приходишь, цветок мой? Почему грустишь и печалишься? Дай мне руку! Открой мне свое сердце! Пусть нашу тайну узнают звёзды!



# V БҮЛЕК

## Җырлашып-биеп кенә

# 32. АУЛАК ӨЙ КИЧӘЛӘРЕ




1. Әй, дусларым! Габдрахман! Габдрәшит!
   Ник утырасыз боек?
   Күрше кызлар аулак өй ясыйлар бит, } 2 тапкыр
   Әйдә, шунда барыйык!

   Бүген атнакич икән бит,
   Кызлар токмач кискәннәр.
   Рәхмәт төшсен бу кызларга,
   Буйга зифа үскәннәр!

   Егетләр килеп җитәләр
   Биергә һәм җырларга.
   Безне бигрәк үз итәләр –
   Рәхмәт төшсен кызларга!

2. Әй, гармунчы дус, утырма йоклап!
   Гармуныңны суза төш!
   Телләренә бер басып җибәр ныклап, } 2 тапкыр
   Кулларыңда бардыр көч!

   Ала мәче, кара мәче
   Күрше кураларында.
   Сикереп төшеп биеп алыйк
   Халык араларында.

И биегез, биегез, шул,
Әнә шулай биегез!
Уйнамагач та көлмәгәч,
Нигә монда килдегез?

3. Матур көйләрне сыздыра тальян,
Яшьләр йөзек салалар.
Аулак чакта сөйгән ярлары белән
Үбешеп тә алалар. } 2 тапкыр

Син дә чибәр, мин дә чибәр,
Кашың сикертеп җибәр!
Мине авылның кызлары
Иң чибәр егет диләр.

Берәү, икәү, өчәү, дүртәү,
Бишәү, алтау, унике.
Унике кыз арасында
Иң чибәре минеке!

4. Әкрен-әкрен биюләр дә бетә,
Аякларны талдырып.
Инде такмак әйтешер вакыт җитә,
Кара-каршы утырып. } 2 тапкыр

Әнә килә автомобиль,
Төягәннәр йомычка.
Ухажёр булып килгәнсез –
Ник йөртмисез подручка?

Әнә килә автомобиль,
Төягәннәр киң каеш.
Үзегезне әллә кемгә
Куясыз, понимаешь!

5. Их, яшь чаклар! Кайда сез, яшь чаклар,
Матур аулак кичәләр,
«Йолдыз санау» белән «морҗа ябулар»,
Без бирешкән вәгъдәләр? } 2 тапкыр

Егетләр шаяртмый калмас,
Кызлар бизәнми калмас.
Егет белән кызлар барда
Уен-көлке һич тынмас!

Биек тауның башларында
Күренәдер бер авыл.
Яшьләр җыелган урында
Бик күңелле була ул.

6. Үтә вакыт, сорап тормый бездән,
Яшьлек тә кайтмас кире.
Тик беркайчан да чыкмас күңелләрдән
Аулак өй кичәләре! } 2 тапкыр

**Молодёжные вечеринки в ауле**

Когда взрослые уезжают в соседний аул повидать родственников, девушки, оставшиеся дома, приглашают в гости молодежь. Песни, танцы до упада, шутки, приколы – все это старинный татарский обычай под названием «Аулак өй».

## 33. ЯҢА ЕЛ ҖЫРЫ



1. Язлар, җәйләр аша үтеп, уңышлар җыеп,
Тагын бер ел узып китте, канатын җәеп.
Ел барышыннан калышмый без бардык атлап,
Дөрес яшәргә тырышып, сабырлык саклап.

**Кушымта:**

Уңышлы булсын дип җәйләр,
Ап-ак юрганнарын җәйгән
Яңа ел белән!
Яңа өметләр тудырган,
Һәр кешене куандырган
Яңа ел белән!

Яңа ел белән! Яңа ел белән!
Барчагызны да котлыйбыз
Яңа ел белән!

2. Без телибез бар яшьләргә саф, матур хисләр.
Беркайчан да керләнмәссен сезнең күңелләр!
Парлыларның мәхәббәте гомерлек булсын!
Парсызларга пар канатын табарга язсын!

**Кушымта.**

3. Без телибез балаларга шатлыклы җәйләр!
Газиз әткәй-әнкәйләргә – озын гомерләр!
Без телибез илебезгә иминлек-байлык!
Без телибез һәммәгезгә исәнлек-саулык!

**Кушымта.**

**Новогодняя песня**

*С Новым годом поздравляю,*
*Счастья и любви желаю*
*Я, друзья, нам всем!*

*Новый год пускай поможет*
*Нам найти решенье сложных,*
*Ключевых проблем!*

*Пусть он принесёт*
*Всем большой доход*
*И пусть добрым и удачным*
*Будет Новый год!*

# 34. КОТЛЫ БУЛСЫН САБАНТУЙ!*




1. Яктырып янсын йолдызлар
   Туган илем күгендә!
   Тырыш хезмәт, саф мәхәббәт
   Булсын безнең күңелдә!

      Җәйнең матур көннәрендә
      Килә безгә ямьле туй!
      Куандырып бар халыкны
      Котлы булсын сабантуй!

2. Яңгырасын сабантуйда
   Дәртле бию көйләре,
   Җилкендерсен күңелләрне
   Тальян гармун телләре!

      Биесәк тә, җырласак та,
      Килешеп тора безгә.
      Сабантуйдан сабый туйлар
      Күбәйсен иде көзгә!

* Равил Гозәиров сүзләре.

3. Уртага чык, батыр егет,
Күрсәт батырлыгыңны!
Япь-яшь кызлар гашыйк булсын,
Күреп матурлыгыңны!

Хезмәттә дә, сәнгатьтә дә
Алдынгы безнең яшьләр.
Сабантуйларда җиңәрлек
Бар әле бездә көчләр!

4. Сабантуйларны үткәрик
Дуслыкта, бердәмлектә.
Тугандашлар һәм кардәшләр
Яшәсен күркәмлектә!

Җәйнең матур көннәрендә
Килә безгә ямьле туй!
Куандырып бар халыкны
Котлы булсын сабантуй!

**Славься, Сабантуй!**

Песня посвящена татарскому национальному празднику – празднику Сабантуй, отмечаемому по окончании посевных работ.

*Позади уж посевная.*
*Веселись, пляши, ликуй!*
*Землю светом озаряя,*
*К нам приходит Сабантуй!*

# 35. КОТЛЫ БУЛСЫН ТУГАН КӨНЕҢ!






1. Таң нуры офыкны юа,
   Талгын җил болытны куа.
   Әкренләп яңа көн туа,
   Ямьле һәм иркен.

   Тик беләсең бит син, иркәм,
   Ул көннең нинди икәнен,
   Зур бүләк сиңа илткәнен,
   Чөнки бит ул көн –

**Кушымта:**

Шатлык көне – синең көнең!
Котлы булсын туган көнең!
Сайрар кошлар бүләк итсен
Сиңа матур җырларын!

Сөеклем минем, бәгырем!
Бәхетле булсын гомерең!
Якты кояш жәлләмәсен
Синнән жылы нурларын!

2. Табыннарны җәйик әле,
   Кунакларны җыйык әле,
   Таңга кадәр җырлыйк әле
   Яшьлек көйләрен.

Тик, моңнар белән кавышып,
Бер синең назлы тавышың
Саф нурга күмәр, җанашым,
Күңел түрләрен!

**Кушымта.**

3. Күңелеңне били назлар,
Йөрәгеңдә шаулый язлар,
Өй түрендә уйный сазлар
Тәбрик моңнарын.

Исәр әле ачы җилләр:
Авыр чаклар булыр җиңел,
Әгәр узсак бергә, иркәм,
Тормыш юлларын!

**Кушымта.**

**С днём рождения!**

*В день рожденья, в день рожденья,*
*Встретив Солнца пробужденье,*
*Ощути Земли движенье*
*И судьбу благослови.*

*Мы желаем в день рожденья*
*К новым целям восхожденья,*
*Всех желаний исполненья*
*И, конечно же, любви!*



# VI БҮЛЕК

## Елмаеп, көлеп кенә

# 36. КАЙГЫРМА, ЧИБӘР ЕГЕТ!




**Е г е т.** Сөйгән кызым алдады:
Миңа шалтыратмады,
Ә мин көн буе көттем,
Сагышка уралып!

**К ы з л а р.** Кайгырма, чибәр егет!
Бу фаҗига түгел бит!
Кызыңның телефоны
Калгандыр ватылып!
(2 тапкыр)

**Е г е т.** Кызым тагын алдады:
Күрешергә килмәде,
Ә мин аны урамда
Көттем төнгә чаклы!

**К ы з л а р.** Кайгырма, чибәр егет!
Бу фаҗига түгел бит!
Саф һавада йөрү бит
Үзе бик файдалы!
(2 тапкыр)

**Е г е т**. Кичә мин, җөрьәт итеп,
Кызны үпмәкче идем,
Ә ул шуны сизде дә
Китте миннән качып!

**К ы з л а р**. Кайгырма, чибәр егет!
Бу фаҗига түгел бит!
Бүтән чакта тормассың
Авызыңны ачып! } 2 тапкыр

**Е г е т**. Кызым тәмам азды бит!
Йөрәгемне өзде бит!
«Мин кияүгә чыгам», – дип
Миңа хәбәр итте!

**К ы з л а р**. Кайгырма, чибәр егет!
Бу фаҗига түгел бит!
Бу бер яктан шатлык бит:
Газапларың бетте! } 2 тапкыр

**Е г е т**. Ничек: газап бетсен, ди?
Нинди шатлык булсын, ди?
Дуслар да: «Карт буйдак!» – дип
Һаман миннән көлә!

**К ы з л а р**. Кайгырма, чибәр егет!
Бу фаҗига түгел бит!
Насыйп булган бәхет бит
Үз вакытында килә! } 2 тапкыр

**Не горюй, красавчик!**

Песня про нерешительного парня, который пытается ухаживать за девушкой, но из-за его нерешительности постоянно что-то идет не так. Парень делится своими проблемами с подругами девушки, подруги дают парню советы.

# 37. СИНСЕЗ ЯШӘҮ МӨМКИН ТҮГЕЛ






1. Гашыйк булдым бер кызга:
   Чибәрлеге чиксез!
   Тиңләр идем йолдызга:
   Күз нурлары тиңсез!

   Сөйгәнемә багышлап
   Яздым шушы җырны.
   Хәзер, сезгә күрсәтеп,
   Җырлап бирәм аны:

**Кушымта:**

Синсез әрни күңел!
Синсез сызлый күңел!
Синсез, назлы гөлкәем,
Яшәү мөмкин түгел!
} 2 тапкыр

2. Куркам сөю сүзләрен
   Әйтергә кызыма.
   Хисләремне аңлат, дип
   Ялындым дустыма.

   Дустым йөз грамм салды да
   Кыз янына барды.
   Кулга гармун алды да
   Бу җырны җырлады:

**Кушымта.**

3. Дустымның җырлавына
   Гашыйк булды бит кыз!
   Аңа кияүгә чыкты,
   Ә мин һаман ялгыз!

Дустыма үпкәләмим –
Үземә үпкәлим.
Эчем пошкан чакларда
Шушы җырны көйлим:

**Кушымта.**

4. Бу җырның ахырында
Әйтик йомгак сүзен:
Сөюнең һәр гамәлен
Һәрчак эшлә үзең.

Юкса, картлык та җитәр,
Калмас авызда теш,
Шунда, кызларны сагынып,
Җырларсың бу килеш:

**Кушымта** *(шышылдап әйтелә)*:

Шиншеж әрни күңел!
Шиншеж шыжлый күңел!
Шиншеж, нажлы гөлкәем,
Яшәү мөмкин түгел!

**Нет жизни без тебя**

Песня еще про одного робкого парня, который влюбился, но, не решаясь признаться в любви своей избраннице, попросил своего друга сделать это за него. Что из этого получилось, всем известно. Мораль:

*«В любви надо действовать смело,*
*Задачи решать самому*
*И это серьёзное дело*
*Нельзя доверять никому».*

# 38. САНДУГАЧЫМ-ГҮЗӘЛЕМ



**Дүртенче куплеттан соң**




1. Синең битеңә карыймын,
   Ник борасың битеңне?
   Синнән кат-кабат сорыймын:
   Ник яратмыйсың мине?

**Кушымта:**

Сандугачым-гүзәлем!
Синсез ничек түзәрмен?
Күңелемдәге өметләрне
Ничек кенә өзәрмен?
} 2 тапкыр

2. Син әйттең: «Миңа кирәкми
   Синдәй җебегән җаннар!»
   Һәм куштың: «Миңа кирәк, – дип, –
   Эх, крутой бизнесменнар!»

**Кушымта.**

3. Син сорадың: «Бармы синдә
   Шестисотый мерседес?
   Бармы җиһазлы фатирың?
   Бармы дачаң, наконец?»

Эх, сандугач-күгәрчен!
Инде син бер түзәрсең,
Бу сорауларга җавапны
Хәзер үк ишетерсең!

4. Зур байлыгым булмаса да,
Күп минем һөнәрләрем!
Хәзер әйтеп бирәм сиңа,
Яхшы тыңлап тор, бәгърем:

Физиканы мин беләм, химияны мин беләм,
Биология беләм, филология беләм.

Компьютерны мин беләм, интернетны да беләм,
Инглиз телен дә беләм, француз телен дә беләм.

Кадакны кага беләм, агачны кисә беләм,
Кер үтүкли дә беләм, стена мүкли дә беләм.

Бакча үстерә беләм, бала тустыра беләм.
Неужели барыбер мин ярамыйм сиңа, иркәм?

**Кушымта.**

**Красавица моя, соловей мой**

Не всё в жизни измеряется деньгами, крутыми машинами и особняками. «Да, я не богат, – говорит герой песни, – но зато у меня столько умений и навыков, что хватит на десятерых. Неужели ты не оценишь богатство моей души и внутреннего мира?»

# 39. ЭХ, ЧИБӘР КЫЗ



1. Беренче кат сине каенлыкта күрдем.
Йөрәгемдә сөю утларын яктың.
Яннарыңа барып тел катмакчы идем –
Каенлыкка чумып, шундук юк булдың!

**Кушымта:**

Эх, чибәр кыз! Кайда соң син?
Һаман сине уйлап, саргаямын мин!
Нурлы йөзләреңне күрәсе иде!
Күзләреңнән үбәсе иде!

2. Икенче кат сине күл буенда күрдем.
Шәфәкъ нурларына соклана идең.
Яннарыңа барып тел катмакчы идем –
Ал нурларга чумып, шундук юк булдың!

**Кушымта.**

3. Өченче кат сине күрдем юл чатында.
Китеп бара идең ерак илләргә.
Белеп кал, җанкаем: синең яннарыңа
Бер барып җитәрмен, ияреп җилгә!

**Кушымта.**

**Эх, красавица!**

В первый раз я увидел тебя в березовой роще. Только ринулся к тебе – ты пропала! Во второй раз я увидел тебя у озера в закатный час. Только рванулся к тебе – ты нырнула в лучи заката, и нет тебя! В третий раз я встретил тебя на развилке дорог – на сей раз ты уезжала насовсем. Но знай, милая: где бы ты ни была, я возьму в помощники ветер и примчусь к тебе; я найду тебя!

# 40. УТ ЯНА






1. Кичә мин сөйгән кызымны кинога алып бардым.
Кинодан соң фатирымда кунакка алып калдым.
Шампан, кәнфитләр әзерләп, утырдым кыз янына.
Башымда төрле уйлар бар, йөрәгемдә ут яна.

Ут яна, ут яна,
Ялкыны көчле микән?
Йөрәгемдә утлар яна,
Кемнәр сүндерер икән?

2. Шампан шешәсен ачканда кинәт өйдә ут сүнде.
Бүлмә эче дөм караңгы, хәзер нишләргә инде?
Кызым янымда утыра, күкрәген миңа терәп.
Кайдан башларга да белмим, котырып тибә йөрәк!

Ут сүнә, ут сүнә,
Сүнгәне хәтәр микән?
Ут сүнгәннән файдалансаң,
Кем сине әрләр икән?

3. Кызым куеныма керде дә: «Күрче, – ди, – нинди рәхәт!
Инде хәзер, ут та сүнгәч, җегетлегеңне күрсәт!»
Җегетлекне күрсәтим дип, бер фужер шампан эчтем,
Пинжәкне салып эттем дә,.. ут рәтләргә керештем.

Ут сүнә, ут сүнә,
Сүнгәне әйбәт микән?
Утны үзең рәтләмәсәң,
Кем килеп рәтләр икән?

4. Ут рәтләнде, тик шул ут бит кәефен кырды кызның.
«Син ахмак, – ди, – ремонт белән бөтен рәхәтне боздың!»
«Ачуланма, бәгырькәем! Ремонт безгә нипочём!
Выключатель дә ярар бит рәхәт кайтарыр өчен!»

Ут яна, ут яна,
Сүндереп була икән.
Ут сүндергәч, ни булганын
Сөйләргә ярый микән?

**Свет горит**

Герой песни сводил девушку в кино на вечерний сеанс, потом привел домой и стал угощать чаем. В этот момент погас свет. Ситуация недвусмысленная. Да и девушка вся в ожидании. Однако герой отправляется менять электрические пробки, чем весьма разочаровывает девушку. Когда вновь загорается свет, девушка попрекает парня, что, дескать, он своим ремонтом испортил всю пикантность обстановки, на что парень отвечает: «Ремонт тут не причем! Есть ведь выключатель, чтобы снова вернуть романтический настрой». О том, что было дальше, по понятным причинам умалчивается.

Песня о том, что сначала – дело, а уже потом – всё остальное.

## 41. ӘЛЛӘ... МИКӘН?



1. Чит иллəрдəн туган илгə
Ашкынып кайтып килəм.
Иген кыры киң җəелгəн:
Əйтерсең, яшел келəм!

Нəкъ шул келəм уртасында
Бер агач үскəн икəн:
Əллə имəн, əллə чыршы,
Əллə алмагач микəн?
} 2 тапкыр

2. Кырлар аша үткəн чакта
Искə төште яшьлегем.
Кузгалды моң-җыр йөрəктə,
Нурланды күңел күгем.

Баш өстемдə кош сайрады:
Ни дип юрарга икəн?
Əллə чыпчык, əллə былбыл,
Əллə бүз тургай микəн?
} 2 тапкыр

3. Кыр читеннəн тау башына
Илткəн юл бигрəк озын.
Тау башында нəкъ каршыма
Чыкты бер авыл кызы.

Ник соң бу кыз, каш сикертеп
Миңа күз ата икəн:
Əллə уйный, əллə көлə,
Əллə ярата микəн?
} 2 тапкыр

**Не то... то ли?**

Текст песни построен на игре слов *əллə* и *микəн* (не то, то ли). Герой песни возвращается из дальних краев в родной аул. По пути домой он сначала видит в степи дерево – не то дуб, не то ель, не то яблоню, потом над его головой пролетают птицы – не то воробьи, не то соловьи, не то жаворонки, и, наконец, на подходе к аулу, к нему навстречу выходит девушка и улыбается. То ли заигрывает? То ли насмехается? А, может, быть, любит? Можно сказать, что песня написана в стиле своего рода шуточной неопределенности.



# VII БҮЛЕК

## Китапның ахырында – төрле нәрсә турында

# 42. ИКМӘК ТУРЫНДА ҖЫР*




1. Урак өсте. Бодай басуыннан
   Хуш исләр һаман аңкып тора.
   Башак алдым: очлы кылчыклары
   Учымны назлап, чәнчеп тора.

---

* Салисә Гәрәева сүзләре.

Учларымда шушы башакларның
Кылчык чәнчүләрен мин тойсам,
Игенченең гүя сөялләнгән
Кытыршы кайнар учын кысам!

**Кушымта:**

Яңа икмәк! Ул – көтелгән, тансык кунак,
Йомры битле, алсу йөзле, үзе гади, үзе тыйнак.
Алга килә, үз кадерен белеп кенә,
Кайнарланып, хуш ис бөркеп һәм елмаеп-көлеп кенә!

Табын хозур! Нурландырып аның түрен
Икмәк тора: рәхим итеп, әйдә, үрел, әйдә, үрел!
Шөкер әле: икмәкле без! Икмәк булса, тормыш та мул!
Гөрләп яшә, бәхетле бул!

2. Дөнья буйлап үттем, авыз иттем
Бик күп халыкларның ашларын.
Туган җирдә үскән икмәктән дә
Тәмлерәк ризык табалмадым.

«Икмәк булса, җыр да булыр», – диеп
Юкка әйтми халык мәкале.
Яшәү ямен чынлап аңлар өчен,
Ярый, җирдә икмәк бар әле!

**Кушымта.**

**Песня о хлебе**

«Хлеб всему голова», «Не трудиться – хлеба не добиться», «Будет хлеб – будет и песня» – с этими пословицами вполне перекликается данная песня. Жизнь богата, если на столе есть хлеб.

## 43. АК БУРАНЫМ – АК КАНАТЫМ*






1. Ак карларны сагындым мин.
   Бик сагындым ак карларны,
   Ак көртләрне, ак өйләрне,
   Ак юрганлы ак кырларны...

   Ак бураным – акбүз атым,
   Утырт та ак канатыңа,
   Илтеп куйчы җилтерәтеп
   Авылыма – җанашыма!

**Кушымта:**

Ак бураным – ак канатым,
Ак бураным – акбүз атым,
Илтеп куйчы җанашыма,
Ак бураным – ак канатым!

2. Илтеп куйчы, ак бураным,
   Авылым бит янда гына...
   Күз яшедәй чиста карлар,
   Ап-ак карлар анда гына.

Шундый сусадым аклыкка,
Ак карларга гашыйк ич мин.
Гомер буе шул аклыкны
Сагыныплар яшим ич мин!

**Кушымта.**

**Белый буран – белая птица**

Герой песни в буранную погоду скачет к своей любимой и призвает буран в помощники. В песне часто употребляется слово «ак» («белый»): белый снег, белые сугробы, белые дома, белые поля под белым одеялом, из-за чего у слушателя возникает ощущение чистоты и непорочности.

# 44. ЯЗЛАРДА*




* Сүзләре Равил Гозәиров белән автордашлыкта язылган.

1. Сибелә кояш нурлары,
Ишетелә шат авазлар.
Яшәртеп бөтен дөньяны,
Килде тагын матур язлар.

**Кушымта:**

Язларда,
Җир ямьләнә язларда,
Очып кайта казлар да,
Сагынып илләрен.

Язларда
Туган сөю, назлар да
Гомерлек булса иде,
Бәгырем!
} 2 тапкыр

2. Уянды урман, кырлар да,
Калын карлар эреп акты,
Ямьләндереп тирә якны
Умырзая чәчәк атты.

**Кушымта.**

3. Бүләк итик сөйгәннәргә
Беренче гөл бәйләмнәрен.
Уйнап-көлеп каршы алыйк
Язның матур бәйрәмнәрен!

**Кушымта.**

**По весне**

Песня о самом светлом времени года, когда в сердцах пробуждаются ростки прекрасного чувства...

*По весне*
*Мир преображается:*
*Птицы возвращаются,*
*И земля в цвету.*
*По весне*
*Верю не напрасно я,*
*Что любовь прекрасную*
*Я найду!*



# 45. ЧИКЛӘВЕК*




1. Карурманга ялгышып мин кердем,*
Бер чикләвек агачын мин күрдем.
Шул урманда югалган, дускаем,
Эх, унсигез яшькәем!..

**Кушымта:**

Яшел чикләвек куагы
Җәелеп үсә икән.
Яшь гомерне сизми калдым,
Бигрәк тиз үтә икән.

Чикләвекләр, чикләвекләр,
Өзим икән кайсысын?
Үткән гомер үткән инде,
Алда булсын яхшысы!

* Сүзләре Тимер Заһит белән автордашлыкта язылган.

2. Күр, дускаем, чикләвек уңганын!
Күп дистәле тәлгәшләре аның.
Шул тәлгәштәй нык булып, берләшеп,
Яшик әле гөрләшеп!..

**Кушымта.**

3. Карурманда адашкан шул көнне
Мин аңладым бер гади нәрсәне:
Күп булса да рәнҗүләр, көюләр,
Бик шәп безнең гомерләр!

**Кушымта.**

**Орех**

Герой песни, заблудившись в лесу, встречает ореховое дерево, усеянное гроздьями плодов; оно вызывает в нем определенные ассоциации и наводит на размышления: хорошо жить в дружбе и единстве; даже если много в жизни обид и разочарований, всё равно жизнь прекрасна и удивительна, и все лучшее у нас еще впереди!

# 46. ДӨРЕС ӘЙТӘСЕЗ, ДУСЛАР!*




1. Көзге җилләр генә бары
Куенга сыенганда,
Өметнең тузган җиләнен
Кияргә җыенганда,

* Фәннүр Сафин сүзләре.

Дуслар миңа болай диде:
«Җир йөзендә шатлык күп!
Кайгылар дип йөргәнебез – кайгы
Түгел, бары чүп.

Өметсезлектән кешенең
Үзендә генә дәва:
Күзге яңгырга үч итеп ләйсән
Күңелдә ява!»

2. Бер уйласаң, безнең сагыш
Кемдә генә булмаган?
Баксаң, язгы гөлләр исе
Аңкып тора дөньядан!

**Кушымта:**

Бик дөрес әйтәсез, дуслар!
Җирдә шатлык күп икән!
Кайгылар дип йөргәнебез кайгы
Түгел, чүп икән.

Өметсезлектән кешенең
Үзендә икән дәва:
Күзге яңгырга үч итеп ләйсән
Күңелдә ява!

3. Ява язгы кояш нуры,
Әйтерсең лә яз килде.
Һәм талпына өмет кошы –
Гүя бу да аз инде!

**Кушымта.**

**Верно говорите, друзья!**

Идея этой песни перекликается с предыдущей: на земле много радости, и часто то, что мы считаем трагедией – на самом деле ерунда. Главное – не терять надежду, а это зависит только от самого человека.



# 47. ЯРАТАМ БИГРӘК МИН, ДУСЛАР




1. Яратам бигрәк мин, дуслар,
   Матур язгы көннәрне,
   Алкалы ак каеннарны,
   Мәһабәт имәннәрне,

      Һавадагы йолдызларның
      Җемелдәп уйнаганын,
      Урмандагы чишмәләрнең,
      Урмандагы чишмәләрнең
      Чылтырап сайраганын! } 2 тапкыр

2. Яратам бигрәк мин, дуслар,
   Безнең дәртле җырларны:
   «Минзәлә» белән «Эрбетне»,
   «Арча» белән «Сарманны».

      Тормышның авыр чакларын
      Җиңел була кичәргә,
      Читкә куеп кайгыларың,
      Читкә куеп кайгыларың
      Җырласаң бу көйләргә! } 2 тапкыр

3. Яратам бигрәк мин, дуслар,
Дус булып яшәгәнне,
Бүтәннәрнең хаталарын
Кичерә белгәннәрне.

Ачу ятмаса күңелдә,
Шәфкатьле булса йөрәк,
Матуррак үтәр гомерләр,
Матуррак үтәр гомерләр, } 2 тапкыр
Дөнья булыр ямьлерәк!

**Песня о том, что я люблю**

*Очень я люблю, ребята,*
*Наши степи, горы кряду,*
*Наши сказки, наши песни,*
*Наши танцы до упаду.*

*И еще люблю я тех, кто*
*Зла в душе таить не смеет,*
*Кто добро творит охотно*
*И других прощать умеет.*

# 48. ТУКРАН*




---

* Нәҗип Мадьяров сүзләре.

1. Тук-тук-тук-тук-тук-тук-тук-тук итеп
Урманда шакылдый ул.
Кем соң? Әллә утынчымы?
Юк, тукран, тукран бит ул!
Кем соң? Әллә утынчымы?
Юк, тукран, тукран, тукран, тукран бит ул!

2. Колагын бер зур агачка терәп,
Һаман нәрсәдер тыңлый.
Кунарга урын табалмый,
Табалмагач, аптырый.
Кунарга урын табалмый,
Табалмагач, табалмагач, аптырый.

3. Менә, ниһаять, урын тапты да
Тукылдата башлады.
Күп тә үтми агачтагы
Кортны табып ашады!
Күп тә үтми агачтагы
Кортны табып, кортны табып ашады!

4. Тук-тук-тук-тук-тук-тук-тук-тук итеп
Урманда шакылдый ул.
Кем соң? Әллә утынчымы?
Юк, тукран, тукран бит ул!
Кем соң? Әллә утынчымы?
Юк, тукран, тукран, тукран, тукран бит ул!

**Дятел**

Веселая детская песенка.

*Он по дереву стучал –*
*От личинок очищал,*
*Столько сил притом потратил.*
*Кто же он? Конечно, дятел!*

# 49. ХӘЕРЛЕ ЮЛ






1. «Хәерле юл!» – ул электән килгән теләк.
   Юлчыларга бу сүз булган һәрчак терәк.
   Без дә сезнең юлыгызга уңыш юллыйк:
   Хәерле юл теләп калыйк.

   Хәерле юл сәфәр чыккан кешеләргә,
   Руль артында хезмәт иткән кардәшләргә,
   Биек күктә самолетта очканнарга,
   Диңгезләрне кичкәннәргә!

**Кушымта:**

Хәерле юл, хәерле юл тели сезгә ак каеннар!
Хәерле юл, хәерле юл тели сезгә якын дуслар!
Хәерле юл, хәерле юл – һәркемгә дә кирәк бит ул,
Хәерле юл, хәерле юл!

2. Хәерле юл хезмәткәрләр-эшчеләргә,
   Мәктәпләргә аяк баскан балаларга,
   Никахланып тормыш корган бар яшьләргә,
   Тәпи баскан сабыйларга!

Җиңел түгел тормышкайның зур юллары,
Була алар сикәлтәле, борылмалы.
Шулай да без, һич тә бирешми аларга,
Җитик куйган максатларга!

**Кушымта.**

**Счастливого пути**

Пожелание доброго пути водителям, летчикам, морякам и всем, кто в пути. А поскольку жизнь – это тоже путь, и самый большой путь, песня превращается в пожелание добра и счастья всем живущим на этой земле.

# 50. САУ БУЛЫГЫЗ, КАДЕРЛЕ ДУСЛАР!



1. Юл йомгагын сүтеп, таулар аша үтеп,
Уралып кайттык туган илгә.
Ак каеннарны да, кыр-басуларны да
Сәламләдек, баш иеп җиргә.

Йөрәкләрдә каткан кар-бозлары
Гөрләвектәй эреп актылар.
Ник соң бик тиз җитте аерылу чаклары
Сезнең белән, кадерле дуслар!

**Кушымта:**

Сау булыгыз, кадерле дуслар!
Сау булыгыз, газиз туганнар!
Янә аера безне язмышыбыз!

Без тагын китәрбез еракка,
Ләкин мәңге калыр йөрәктә
Сезнең җылы карашыгыз!

2. Яшьлек билгеләре – мәхәббәт көйләре
Яңгырый күңелләрдә һаман.
Бергә булулары – бәхет минутлары,
Аерылу гына бигрәк яман.

Кайсы гына илдә яшәсәк тә,
Чыкмас күңелдән туган яклар.
Ходай насыйп итсә, очрашырбыз әле,
Күрешербез, кадерле дуслар!

**Кушымта.**

**До свидания, дорогие друзья!**

Финальная песня с выражением благодарности и надежды на будущие встречи. Может быть использована как заключительная песня концертной программы.

## ҖЫЕНТЫК ТУРЫНДА ФИКЕР

Алматада туып үскән һәм хәзерге вакытта шунда яшәп иҗат итүче Шамиль Сагаутдинов минем өчен яңа танышым.

Аның “Илле җырым – йөрәк нурым” исемле җыентыгын карап чыкканнан соң, Татарстаннан читтә яшәүче, җитмәсә һөнәре буенча сәнгать кешесе булмаган милләттәшемнең үз халкының киләчәге турында тирәнтен уйланулары, җыр, музыка аша татар халкының гореф-гадәтләрен саклап калырга тырышуы мине сокландырды.

Әлбәттә, эти-әнисе аны татар рухлы итеп тәрбияли алган, милли җырларыбызны, мәдәниятыбызны канына сеңдергән. Бәхәссез, Шамиль талантлы, тырыш егет. Ул эзләнә, кабатланмас темалар эзли, җырларының сүзләрен дә, көйләрен дә үзе язарга, чыганакларга якынаерга тырыша.

Шамиль җырларының тематикасы төрле-төрле. Ул аларны җиде кисәккә бүлеп бирә: туган ил, эти-әни, мәхәббәт җырлары һ.б. Берсеннән - берсе матур хатын-кыз исемнәренә багышланган унике җыр үзе бер бүлекне тәшкил итә.

“Ак бураным – ак канатым” җырында синкопа бик әйбәт кулланыла, акбүз атның чабышын, егетнең мәхәббәтенә ашкынуын музыкада тулысынча ишетәбез.

“Дөрес әйтәсез, дуслар” – бу җыр татар халык җырына якынайтып язылган, сүзләре көйгә тәңгәл килә. Җырның, минем фикеремчә, киләчәге бар.

“Тукран” җырында музыка җыр сүзләренең мәгънәсен ача.

“Кайгырма, чибәр егет” җырында, минемчә, ноталардагы ярты тонлы хроматикалар артык. Әгәр дә алар булмаса, матур гына татар көе килеп чыгар иде.

“Бер син генә “ җырында бер-бер артлы ике зур терцияне кулланып (ля – до диез – фа) татар милли интонациясеннән чыгып китә. Алар билгеле төсмер бирсә дә, татарга ят музыка булып кала.

“Гөлгенәм” җырында безнең халыкта сирәк очрый торган, Салих Сәйдәшевнең ”Әдрән диңгез”ендә, Илһам Шакировның “Син сазыңны уйнадың”да булган, шәрык көйләренә хас интонацион элементлар

кулланылган. Әмма әлеге әсәрләрдә бу элементлар бик отышлы кулланылып, әсәрнең эчтәлеген тагын да тирәнәйтеп, баетып татар җырының матур бер үрнәге булып торсалар, Шамиль Сагаутдиновның “Гөлгенәм” җыры татар җыры булып китә алмаган.

Әйткәнемчә, Шамиль эзләнә, җырларына үзенчәлекле аһәң өстәгән кабатланмас музыкаль интонация элементлары – синкопалар, ярты тонлы секундалар, гармонияләр – табарга тырыша. Әгәр дә шушы илле җырның берсе генә булса да халык күңелендә кала икән – ул инде бәхетле иҗатчы музыкант.

Риф Гатауллин

композитор,<br>
атказанган сәнгать эшлеклесе,<br>
РФ һәм ТР композиторлар<br>
берлеге әгъзасы,<br>
М.Җәлил исемендәге<br>
премия лауреаты

## ПЕСНИ, ДАРУЮЩИЕ РАДОСТЬ

Автора сборника песен «Илле жырым – йөрәк нурым» я знаю давно. Шамиль Сагаутдинов принадлежит к тому сорту людей, которые умеют получать истинное удовольствие в развитии свыше данных способностей и талантов, умеют наслаждаться процессом бескорыстного созидания и творения. Наверное, поэтому такие люди одарены многосторонне и развиваются в разных, подчас не пересекающихся, направлениях. Математик по профессии, кандидат физико-математических наук, поэт и композитор по призванию, замечательный певец, обладающий красивым тембром и широким диапазоном голоса... Не забыть упомянуть, что Шамиль свободно и одинаково грамотно владеет несколькими языками, а также неплохо разбирается в современных компьютерных технологиях.

Сочинение песен для Шамиля не является источником материального обогащения. Вероятно, это веление души, внутренняя потребность, которая – хочет он того или нет – все же обогащает. Обогащает духовно и интеллектуально. Могу сказать, что, в отличие от многих самодеятельных авторов, Сагаутдинова выгодно отличает художественный вкус, тщательность в работе, особая требовательность к себе. Важно, что автор, будучи опытным певцом, прекрасно знает вокальные тонкости и возможности человеческого голоса. Поэтому его песни удобны, комфортны для исполнения. Их приятно петь, их приятно слушать.

В песнях из сборника отражены разные сферы чувств и настроений. Тематика и содержание – то, что близко и ценно каждому из нас: любовь к родным и близким, любовь к женщине, верность дружбе, почтение и сыновняя благодарность родителям, теплое чувство к родной земле, восхищение природой родного края... Мелодии песен напевны, большинство из них имеет национальную основу – характерные для татарской музыки ритмы, лады и мелодические обороты. Автор прекрасно знаком как с фольклорной музыкой, так и с классикой татарского романса. Иногда в песнях как бы проскальзывает «отсылка», почтительный «поклон» основоположникам профессиональной татарской вокальной музыки: Саре Садыковой, Рустему Яхину. Часть песен выдержана строго в стиле народных напевов. Мелодии Шамиля Сагаутдинова – это продолжение, развитие, сохранение татарской национальной музыки, ее жизнь и цветение.

Хочется отметить особую задушевность лирических песен. Искренние теплые чувства вызывает красивая, мелодичная песня, посвященная маме – «Әнкәйгә теләкләр». Песню «Кавышыйк без» хотелось бы услышать в исполнении певца, владеющего народной традицией пения – с мелизмами, орнаментацией напева. Получилась бы настоящая традиционная протяжная песня – озын көй. Замечательны песни, говорящие о самом сильном из

чувств – о любви: пылкая «Бер син генә», печальная «Җил», изящная «Язларда», невероятно напевная и сердечная «Бик сагындым сине».

Интересен и удачен раздел сборника, посвященный **именам**, своего рода «проект». Самые красивые женские имена – как цветы в одном букете. Каждое имя заключает свой характер и образ. Поэтичная «Акйолдыз» и строгая «Гөлназым», кокетливая «Гөлфия» и серьезная «Гүзәлия», благородная «Лилия» и далекая недоступная «Резеда». Каждая песня – подарок девушке. Хочется подчеркнуть, что в данном «букете» нет броских новомодных имен. Шамиль воспевает старинные, по-настоящему красивые, поэтичные татарские имена. И это замечательно! Хотелось бы пожелать каждой девушке обладать своей красивой песней.

В сборнике немало веселых, шуточных песен. Жизнерадостная плясовая мелодия у песни «Шахмай авылы», шуточная «Кайтам туган ягыма», веселая «Сәгатьләр», изящная и филигранная «Аулак өй кичәләре», остроумные «Сандугачым-гүзәлем» и «Ут яна». Эти песни будут к месту на любом празднике. В любой компании они способны поднять настроение, помочь забыть о плохом и порадоваться жизни.

Есть в книге и ряд тематических песен, песен-посвящений. Песни о родном крае – «Мин яратам сине, Казакъстаным!» и «Алматы турында җыр» – просто требуют перевода текстов на казахский и русский языки. Такие песни всегда востребованы, ведь каждый праздник нуждается в новых песнях. Сюда же отнесу мелодичные, напевные «Яңа ел җыры», «Котлы булсын сабантуй», «Котлы булсын туган көнең». Нужные, хорошие песни.

Немного жаль, что Шамиль не увлекся (надеюсь, пока еще не увлекся) жанром детской песни. В книге представлена всего одна, но достаточно яркая, привлекательная песенка для детей – «Тукран». Судя по ней, автор мог бы создать качественные (и очень нужные!) песни для самых маленьких. Востребованность данного жанра гарантирована, правильных детских песен не так уж много.

Один знакомый фольклорист рассказывал мне об исследованиях терапевтического воздействия музыки разного вида. Он говорил, что обнаружился совершенно уникальный оздоровительный эффект мелодий, звучащих в пентатонном ладу – ладу, характерном для татарских народных песен. Не знаю, насколько точны были исследования. Но после песен Шамиля Сагаутдинова я почувствовала особенную легкость. Как будто стало больше воздуха и света, тепла и уюта.

Успехов тебе, Шамиль!

Рамзия Валиуллина — кандидат искусствоведения, доцент

## МУЗЫКАЛЬНОЕ ПРИЛОЖЕНИЕ на CD-диске

1. Алматы турында җыр
2. Җилләр исә
3. Шахмай авылы
4. Кайтам туган ягыма
5. Әткәйгә сәлам
6. Әнкәйгә теләкләр
7. Шәрык кызы Зәринә
8. Гөлнирәм
9. Чибәр кыз Гөлүсә
10. Гөлфия
11. Гүзәлия
12. Дилбәр, Дилбәркәем
13. Гөлгенәм
14. Аулак өй кичәләре
15. Яңа ел җыры
16. Котлы булсын сабантуй!
17. Икмәк турында җыр
18. Язларда
19. Яратам бигрәк мин, дуслар
20. Хәерле юл
21. Алматы турында җыр-*минус*
22. Җилләр исә-*минус*
23. Шахмай авылы-*минус*
24. Кайтам туган ягыма-*минус*
25. Әткәйгә сәлам-*минус*
26. Әнкәйгә теләкләр-*минус*
27. Шәрык кызы Зәринә-*минус*
28. Гөлнирәм-*минус*
29. Чибәр кыз Гөлүсә-*минус*
30. Гөлфия-минус-*минус*
31. Гүзәлия-минус-*минус*
32. Дилбәр, Дилбәркәем-*минус*
33. Гөлгенәм-*минус*
34. Аулак өй кичәләре-*минус*
35. Яңа ел җыры-*минус*
36. Котлы булсын сабантуй! -*минус*
37. Икмәк турында җыр-*минус*
38. Язларда-*минус*
39. Яратам бигрәк мин, дуслар-*минус*
40. Хәерле юл-*минус*

# Э Ч Т Ә Л Е К / С О Д Е Р Ж А Н И Е

**Кереш сүз** ........ 3

**Предисловие** ........ 5

**I БҮЛЕК. Туган илем – сөйгән җирем** ........ 7

1 Мин яратам сине, Казахстаным! ........ 8
2 Алматы турында җыр ........ 10
3 Җилләр исә ........ 12
4 Бүз тургайлы кырлар, карлыгачлы ярлар ........ 13
5 Шахмай авылы ........ 15
6 Кайтам туган ягыма ........ 17

**II БҮЛЕК. Безнең әти-әниләр – иң кадерле кешеләр** ........ 20

7 Әткәйгә сәлам ........ 21
8 Әнкәйгә теләкләр ........ 22

**III БҮЛЕК. Чын бәхет офыклары – мәхәббәт чаткылары** ........ 24

9 Сәгатьләр ........ 25
10 Минем мәхәббәтем ........ 26
11 Мәхәббәт сүрелми ........ 27
12 Яннарымда син булганга ........ 29
13 Ай сөярмен, ел сөярмен ........ 30
14 Бик сагындым сине ........ 32
15 Кавышыйк без........ 34
16 Бер син генә ........ 35
17 Җил ........ 36
18 Үбәр идем күзләреңнән ........ 37
19 Сүнмәсен өметләрең ........ 39

**IV БҮЛЕК. Иҗатым җимешләре – хатын-кыз исемнәре** ........ 41

20 Акйолдыз ........ 42
21 Гөлгенәм ........ 43
22 Гөлназым ........ 45
23 Гөлнирәм ........ 46
24 Чибәр кыз Гөлүсә ........ 48
25 Гөлфия ........ 50
26 Гүзәлия ........ 52
27 Дилбәр, Дилбәркәем ........ 53
28 Шәрык кызы Зәринә ........ 55
29 Лилия ........ 57
30 Бәхетле бул, Нурия! ........ 58

31 Резеда, бәгырькәем .......................................................................... 59

**V БҮЛЕК. Җырлашып-биеп кенә** .......................................................... 62

32 Аулак өй кичәләре .......................................................................... 63
33 Яңа ел җыры .................................................................................... 65
34 Котлы булсын сабантуй!.................................................................. 67
35 Котлы булсын туган көнең!............................................................. 68

**VI БҮЛЕК. Елмаеп, көлеп кенә** ............................................................ 71

36 Кайгырма, чибәр егет! ..................................................................... 72
37 Синсез яшәү мөмкин түгел .............................................................. 73
38 Сандугачым, гүзәлем ....................................................................... 75
39 Эх, чибәр кыз! ................................................................................. 77
40 Ут яна .............................................................................................. 78
41 Әллә... микән? .................................................................................. 80

**VII БҮЛЕК. Китапның ахырында – төрле нәрсә турында** ............... 82

42 Икмәк турында җыр ......................................................................... 83
43 Ак бураным – ак канатым ................................................................ 84
44 Язларда ............................................................................................ 86
45 Чикләвек .......................................................................................... 88
46 Дөрес әйтәсез, дуслар! ..................................................................... 89
47 Яратам бигрәк мин, дуслар .............................................................. 91
48 Тукран .............................................................................................. 92
49 Хәерле юл ........................................................................................ 93
50 Сау булыгыз, кадерле дуслар! ......................................................... 95

**Җыентык турында фикер** .................................................................... 97

**Песни, дарующие радость** ................................................................... 99